# Түгәрәк уен

ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ 4 / 2020

Хәситә – татарларның этник төркемнәренә хас традицион бизәнү әйбере. Ювелир бизәкләр тезеп тегелгән буй тукыма сул як җилкәдән күкрәккә төшерелгән һәм уң кул астыннан үтеп, аркадан каптырылган. XVII-XVIII йөз картиналары күчермәләрендә Сөембикә ханбикәнең дә кыйммәтле күкрәк бәйләвече, түшелдерек йөрткәне күренә.







Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

Фәнис ЯРУЛЛИН

# Каз өмәсе

*Фәрештәләр каз өмәсе ясый,*
*Күктә бүген хәйран тамаша.*
*Бөтерелеп очкан ак мамыктан*
*Баш әйләнә, күзләр камаша.*

*Күктән килә шаян җыр тавышы,*
*Бу җырлардан йөзләр нурлана.*
*Муеннарга кызлар кулы булып*
*Ак мамыклы буран урала.*

*Урала да буран, җибәрми һич,*
*Алып менеп китә биеккә.*
*Фәрештәләр казлар йолыкканда*
*Эш табыла һәрбер егеткә.*

*Берсе айны каз читенә элә.*
*Берсе чайкый ап-ак болытта.*
*Күк кызының кызыл бармакларын*
*Җир егете өреп җылыта.*

*Уен белән тормыш кушылган да*
*Бер хозурлык туган галәмдә.*
*Бәхетле Ай гармун уйнап тора,*
*Җилләр бии әйлән-бәйләнгә.*

*Каз өмәсе бүген, наз өмәсе,*
*Ак бураннан күзләр камаша.*
*Әллә күктә казлар каңгылдаша,*
*Әллә яшь йөрәкләр аңлаша.*
*Күк йөзендә хәйран-тамаша.*

*1997 ел*



# Түгәрәк уен

№ 4 2020

16+ Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах

Гамәлгә куючылар:
Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгы каршындагы
Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге

Редколлегия:
Ирада Әюпова
Марсель Бакиров
Разил Вәлиев
Тәлгат Галиуллин
Дания Заһидуллина
Марс Тукаев
Фәрит Юсупов

Директор: Алсу Равил кызы Мифтахова
Баш мөхәррир: Рәзинә Әхтәм кызы Исмәгыйлева

Альманахның иҗат төркеме:
Гөлназ Латыйпова
Рәмзия Гайфетдинова
Илнара Гәрәева

Дизайнер һәм биткә салучы: Диләрә Нәүрузова

Альманах 2020 елның 13 ноябрендә элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр даирәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79590. Журнал өч айга бер чыга. Бәясе ирекле.

Кәгазь форматы 60×90 ⅛. Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды: 21.12.2020
Чыгу көне: 29.12.2020
Заказ: 061573
Тираж: 1000 экз.

Редакция һәм нәшер итүче:
420021, Казан, Тукай ур., 74 а.
Хатлар язар өчен адрес:
420015, Казан, Пушкин ур., 66/33
Телефон: 293-27-99.
E-mail: tugarakuen@mail.ru

«Визарт» ҖЧҖндә бастырылды.
Казан, Җиңү проспекты, 78

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый. Кучереп басканда, «Түгәрәк уен» альманахына сылтама ясау мәҗбүри.

**Тышлыкта:** Хәситә фрагменты. XIX гасыр. А.Ф. Лихачев коллекциясеннән. Татарстан Республикасы Милли музее архивынннан

© «Түгәрәк уен», 2020

*Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,*
*моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.*
*Г. Тукай*

**ТАТАР ДӨНЬЯСЫНЫҢ ТРАДИЦИОН МӘДӘНИЯТЕ ЯҢАЛЫКЛАРЫ**

4 **«Идел-Йорт»: халык театрлары ярышты**

6 **Казанда декоратив-гамәли сәнгатьне үстерү турында фикерләштеләр**

8 **«Сөйкемле Шүрәле» – оста куллар бәйгесе**

**ТАССРның 100 ЕЛЛЫГЫ**

10 **«Минем тарих – Минем Татарстан» Бөтенроссия иҗат конкурсына нәтиҗә ясалды**

14 Д. Шаһабиева
**Без итек басабыз**

**ХАЛКЫМНЫҢ ОСТА КУЛЛАРЫ**

16 Л. Саттарова
**Хәситә феномены**

**ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КҮРКӘМ ЙОЛАЛАРЫ**

22 Л. Мөхәммәтҗанова
**Елап барсаң, көлеп яшәрсеңме яки рухи мирасыбызда сыктаулар**

26 Э. Нәбиуллина
**Гаяз Исхакыйның «Остазбикә» повестендәге туй йолалары**

28 **«...Ялчылаган кызыбызны алмый калыр димәгез»**

29 Г. Нур
**Милли туйларны Татарстанда никахлар саклый**

32 З. Брусько
**Татарларда бәби ашы китерү йоласы**

34 **Татар халкының матур йоласы – каз өмәсе**
















**МИЛЛИ УЕН КОРАЛЛАРЫБЫЗ**

36 Г. Макаров
**«Аһ, синең таушың, канун, чын сихерле могъҗиза...»**

**МУЗЫКАЛЬ МИРАС**

39 Н. Яхина
**Әй, дүдәме, дүдәме, гармунчыгыз өйдәме?..**

**ҺӨНӘРЛЕ ҮЛМӘС...**

41 Л. Хәйриева, З. Гайсина
**Һәр бизәктә – күңел җылысы**

44 Р. Нигъмәтуллина
**Айгөл Сингатуллина: «Милли кием көндәлек була ала»**

**БЕЗНЕҢ КИТАПХАНӘ**

48 **Борынгы әсәрләребездән «Бабахан дастаны»**

**БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК...**

52 **Нардуган**

53 **Игелекле Илтуган**

54 **Нардуган – халык бәйрәме**

55 **Кыш көне** *(җыр)*

56 А. Гарипова
**«Әбиемнең серле сандыгы»**
*(Мәктәпкә әзерлек төркеме өчен сценарий)*

**ӨЙ КҮРКЕ – АШ**

60 **Тутырган тавык**

**ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ**

64 **Шахворд**

## «ИДЕЛ-ЙОРТ»: ХАЛЫК ТЕАТРЛАРЫ ЯРЫШТЫ

Идел-Йорт

**Шамил Закиров исемендәге XX «Идел-йорт» татар театр коллективлары төбәк-ара конкурсы тәгәлләнде. Аны Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры ярдәме белән Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге, Бөтендөнья татар конгрессы оештырды. Фестиваль ТАССРның 100 еллыгына һәм Бөек Җиңүнең 75 еллыгына багышланды. Быел әлеге һәвәскәрләр театрлар фестивален Казан мәдәният йортларында уздырып булмады: аның объектив сәбәпләре бар – пандемия комачаулады. Шунлыктан, фестивальнең икенче этабында видеоязмалар каралса, өченче этабында жюри спектакльләрне онлайн карап бәяләде.**

Икенче этапта жюри әгъзаларына 37 спектакль карарга туры килде.

Өченче этапка аның 12се сайлап алынды:

– Мөслим районының Иске Карамалы мәдәният йорты «Замандаш» халык театры;



«Җир белән күк арасында» (Талха Гыйниятуллин) спектакленнән күренешләр.
Фоторәсем Актаныш районы Киров авылы мәдәният йорты халык театры архивыннан

– Актаныш районы Киров авылы мәдәният йорты халык театры;

– Бөгелмә районы мәдәният йортының «Изһар» халык театры;

– Мамадыш районы мәдәният йорты халык театры;

– Ютазы районы мәдәният йортының «Маски» халык театр студиясе;

– Актаныш районы Иске Сәфәр авылы мәдәният йорты халык театры;

– Менделеевск районы Бизәкә авылы мәдәният йортының «Елмай» театр коллективы;



«Галиябану» (Мирхәйдәр Фәйзи) – «Сөюләрең чыннан булса...» (Раушан Шәриф үзгәртелешендә) спектакленнән күренешләр.
Фоторәсем Биектау районы мәдәният йорты үзешчән театры архивыннан



**«Тол хатыннар. Тол кызлар» (Сәет Шәкүров) спектакленнән күренешләр.**
**Фоторәсем Минзәлә районы Тауасты Байлар авыл мәдәният йортының «Нур» халык театры архивыннан**

– Чаллы шәһәренең «Эврика» музыкаль һәвәскәр театры;

– Минзәлә районы Тауасты Байлар авылы мәдәният йортының «Нур» халык театры;

– Балтач районы мәдәният йорты халык театры;

– Кама Тамагы районы Теньки (Тәмте) мәдәният йортының «Новый образ» театр коллективы;

– Биектау районы мәдәният йорты үзешчән театры.

Халык театрларының репертуарлары киң. Арада Мирхәйдәр Фәйзинең легендар «Галиябану»ыннан башлап, татар язучылары Вакыйф Нуриев, Талха Гыйниятуллин, Фоат Садриев, Айгөл Әхмәтгалиева, Әнгам Атнабаев, Аяз Гыйләҗев, Зөләйха Минһаҗева, Сәет Шәкүров, Ренат Харис һәм башкаларның әсәрләре бар. Финалга чыккан спектакльләрнең икесен рус телле театр коллективлары куйды.

Быел конкурсның жюри составын танылган театр белгече, Камал театрының махсус проектлар кураторы Нияз Игъламов җитәкләде. Аның командасында Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Әзһәр Шакиров, Татарстанның халык артисты Луара Шакирҗанова, сәнгать фәннәре докторы Рауза Солтанова, Татарстан язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Татарстанның атказанган артисты Зөлфия Вәлиева, композитор, сәнгать фәннәре кандидаты Эльмира Галимовалар бар иде.

**Гран-при**га ия булган Актаныш районы Киров авылы мәдәният йорты халык театры Талха Гыйниятуллинның «Җир белән күк арасында» спектаклен (режиссеры Алсу Хуҗина) 21 декабрьдә Г. Камал исемендәге татар дәүләт театры сәхнәсеннән күрсәтте.

**1 нче дәрәҗә лауреат:**

– Сәет Шәкүровның «Тол хатыннар, тол кызлар» спектакле өчен Минзәлә районы Тауасты Байлар авылы мәдәният йортының «Нур» халык театры (режиссеры Мөслимә Гайниева);

**2 нче дәрәҗә лауреатлар:**

– Әнгам Атнабаевның «Ана хөкеме» спектакле өчен Актаныш районы Иске Сәфәр авылы мәдәният йорты халык театры (режиссеры Айзирә Фәхриева);

– Айгөл Әхмәтгалиеваның «Баш куям тезләреңә» спектакле өчен Мамадыш районы мәдәният йорты халык театры (режиссеры Зөлфирә Дәүләтшина);

**3 нче дәрәҗә лауреатлар:**

– Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» спектакле өчен Биектау районы мәдәният йорты үзешчән театры (режиссеры Раушан Шәриф);

– Ренат Харисның «Күзләреңнән үбеп» (режиссерлары Раил Нигъмәтҗанов, Рамил Борһанов) Балтач районы мәдәният йорты халык театры.

## КАЗАНДА ДЕКОРАТИВ-ГАМӘЛИ СӘНГАТЬНЕ ҮСТЕРҮ ТУРЫНДА ФИКЕРЛӘШТЕЛӘР

**Быелның 1-4 декабрь көннәрендә Казанда «Татарстанның декоратив-гамәли сәнгате: традицияләр һәм инновацияләр» уку-укыту семинары узды. Ул – Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләрне саклау ресурс үзәгенең уртак проекты иде.**

**Әлеге чараның төп максаты – Татарстан Республикасында халык һөнәрләре һәм декоратив-гамәли сәнгатьнең традицион төрләрен үстерү һәм җәелдерү. Проект халык сәнгате, аның тарихы, үсеше белән киң катлам укучыны таныштыру, декоратив-гамәли сәнгать өлкәсенә яшь буынны җәлеп итүне күздә тотты.**

Семинарда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге җитәкчесе, сәнгать фәннәре докторы Рауза



Солтанова, Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәгенең директор урынбасары Гөлназ Латыйпова катнашты.

Семинарда катнашучыларга сәнгать белгече Людмила Шкляева татар халкының агач эшкәртү сәнгате турында сөйләсә, рәссам Ринат Әхмәтов агачны сәнгати эшкәртү буенча мастер-класс үткәрде.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының этнологик тикшеренүләр бүлеге фәнни хезмәткәре Динә Гатина-Шәфыйкова Казан татарларының костюмы һәм зәркән сәнгате тарихы белән таныштырды. Изү, хәситә, яка чылбыры, бөти, чулпы, каптырма һәм татар костюмының



башка үзенчәлекле төрләре турында сөйләде. Динә ханым, шәһәрнеке кебек купшы һәм бай булмаса да, кызыклы булган авыл халкы костюмнарына да тукталды. Зәркәнче-реставратор Рәфкать Мөхәммәтшин Идел буе халыкларында зәркән сәнгате технологияләрен аңлатып, үзенең эш үрнәкләрен тәкъдим итте. Сәнгать белгече, рәссам Рөстәм Шәмсутов заманча гарәп-графика сәнгате турында мәгълүмат бирде. Рәссам һәм галим Нәҗип Нәккаш каллиграфия буенча мастер-класс үткәрде, гарәп язуының үзенчәлекләре турында сөйләде, үзе иҗат иткән тугра, мөһер үрнәкләре белән таныштырды. Туксанынчы елларда яңа





үсеш алган шәмаил сәнгате бүген дә популярлыгын югалтмый дип саный алар. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәре Венер Госманов татарда эпиграфик сәнгате тарихы белән таныштырды.

Семинарда шулай ук Идел буе халыкларының алтынлап чигү үзенчәлекләре, төрки дөньяда киез сәнгате, күн мозаикасы хакында лекцияләр укылды. Шулай ук киез һәм күннән эшләнмәләр ясау мастер-класслары узды.



Дмитрий Петриченко фоторәсемнәре

## «СӨЙКЕМЛЕ ШҮРӘЛЕ» – ОСТА КУЛЛАР БӘЙГЕСЕ

**Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге, Бөтендөнья татар конгрессы, «Ак калфак» татар хатын-кызлары иҗтимагый үзәге оештырган «Сөйкемле Шүрәле»-«Обаятельный Шурале» иҗат эшләре конкурсы нәтиҗәләре 2021 елда билгеле булачак. Илдәге санитар-эпидемиологик вазгыятьне күздә тотып шундый карарга киленде.**

Бәйгенең төп максаты – бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның иҗади мирасын популярлаштыру, заманча декоратив-гамәли сәнгатьтә халык традицияләрен саклау.

Конкурска чигелгән, тукылган, челтәләп үрелгән, киез һәм күннән ясалган эшләнмәләр; кулдан ясалган балчык, талчыбык, текстиль, агач уенчыклар, витраж һәм агач юну техникасы белән эшләнгән әйберләр кабул ителде. Конкурсантларның яше – 7 дән 21 яшькәчә иде.

«Сөйкемле Шүрәле»-«Обаятельный Шурале» конкурсының шартлары буенча, 2020 елның 1 апреленнән 31 июленә кадәр читтән торып сайлап алу турлары узды. Әлеге вакыт эчендә 387 гариза кабул ителде.

Жюри Татарстанның 29 районыннан һәм чит өлкәләрдән 152 эшне сайлап алды. Катнашучылар арасында Башкортстан, Марий Эл, Мәскәү һәм Мәскәү өлкәсе, Иваново, Екатеринбург, Ростов, Курган, Свердловск, Чиләбе өлкәләре, Пермь крае иҗатчылары бар.

2021 елда «Сөйкемле Шүрәле»-«Обаятельный Шурале» конкурсы лауреатларының эшләреннән күргәзмә оештырылып, җиңүчеләр билгеләнер дип күздә тотыла.



Ильяс Камалетдинов (9 яшь) эше,
Арча, Лесхоз мәктәбе



Михаил Акимов (12 яшь) эше,
Бөгелмә районы, «Душа древа» студиясе



Диләрә Насыйрова (14 яшь) эше,
Зәй, Югары Налим мәдәният йорты



**Зөһрә Сәрвәрова (15 яшь) эше,
Актаныш балалар сәнгать мәктәбе**



**Аделина Зарипова (14 яшь) эше,
Лениногорск, М.Х. Хәертдинов исемендәге балалар сәнгать мәктәбе**



**Снежана Семенычева (11 яшь) һәм
Вероника Кузнецова (11 яшь) эше,
Лениногорск, М.Х. Хәертдинов исемендәге балалар сәнгать мәктәбе**

Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

# «МИНЕМ ТАРИХ – МИНЕМ ТАТАРСТАН»
## Бөтенроссия иҗат конкурсына нәтиҗә ясалды




Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «Минем тарих – Минем Татарстан» Бөтенроссия иҗат конкурсына нәтиҗә ясалды һәм җиңүчеләр бүләкләнде.

Оештыручылар – Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге.

Бәйге татар халкы турында тарихи хәтерне саклау, яшь буынны патриотик тәрбияләү, туган як һәм нәсел тарихын өйрәнергә этәрү максатларында үткәрелде. Оештыручылар бәйге аша гаилә һәм башка архивлар белән эшләргә омтылучылар артыр, кызыклы документлар һәм фотоматериаллар дөньяга чыгар дип тә ышана.

Иҗади эшләр ике телдә һәм биш номинациядә кабул ителде.

Җиңүчеләр яшь буенча өч төркемгә – 12-17 яшь, 18-21 яшь, 22 яшьтән өлкәннәр – бүлеп билгеләнде.

Бәйгегә кабул ителгән 422 эштән 60ы икенче этапка үтте. Өченче этапта биш номинациядә 33 җиңүче билгеләнде.










**«МОЯ СЕМЬЯ» – «МИНЕМ ГАИЛӘМ» НОМИНАЦИЯСЕ**

**I дәрәҗә лауреатлар:**

– Альбина Токранова «Минем гаиләм – укытучылар династиясе» эше өчен;

– Люция Мөхәммәтшина «Моя история – мой Татарстан!» эше өчен;

– Альберт Хисамов «Золотой ветер. Казань военного времени» эше өчен.

Лауреатларга ноутбукка сертификат тапшырылды.

**II дәрәҗә лауреатлар:**

– Александр Куриненко «Трудовой путь моего дедушки» эше өчен;

– Дилә Шаһабиева «Ләззәт китергән шөгыль» эше өчен;

– Кристина Дьяченко һәм Тәнзилә Гаделшина «Семейные традиции Сагдиевых переходящее из поколения в поколение» эше өчен.

Лауреатлар планшетка сертификат белән бүләкләнде.

**III дәрәҗә лауреатлар:**

– Марат Кәлимуллин «Горурланыр туганнарым» эше өчен;

– Алина Порфирьева «Педагогическая династия в истории моего села» эше өчен;

– Ландыш Сиражетдинова «Олы йөрәкле әбием» эше өчен.

Лауреатлар кәрәзле телефонга сертификат белән бүләкләнде.



«УДИВИТЕЛЬНЫЕ ЛЮДИ» –
«ГАҖӘЕП КЕШЕЛӘР» НОМИНАЦИЯСЕ

**I дәрәҗә лауреатлар:**

– Илья Ледяев, Илгиз Гыйльфанов «Танкист, который участвовал в парадах» эше өчен;

– Гөлүзә Бондарева «Шоколадка от Черчилля» эше өчен.

Лауреатлар ноутбукка сертификат белән бүләкләнде.

**II дәрәҗә лауреатлар:**

– Зиля Нурмөхәммәтова «Бер фото тарихы» эше өчен;

– Валерий Хәйруллов «Знаменитые люди Казани» эше өчен.

Лауреатлар планшетка сертификат белән бүләкләнде.

**III дәрәҗә лауреатлар:**

– Камилә Билалова «Наследие прадедушки» эше өчен;

– Люция Урманчева, Әлфирә Шәйдуллина, Алмаз Шәйдуллин «Человек с непоседливой душой» эше өчен.

Лауреатлар кәрәзле телефонга сертификат белән бүләкләнде.

«РОДНАЯ ЗЕМЛЯ» – «ТУГАН ҖИР»
НОМИНАЦИЯСЕ

**I дәрәҗә лауреатлар:**

– Илнар Идиятов «Я вырос здесь и край мне этот дорог» эше өчен;

– Ирина Халикова «Мой край Азнакаево» эше өчен.

Лауреатлар ноутбукка сертификат белән бүләкләнде.

**II дәрәҗә лауреатлар:**

– Арина Саурова «Мой Татарстан» эше өчен;

– Зөлфия Хәлиуллина «Бу минем туган авыл» эше өчен.

Лауреатлар планшетка сертификат белән бүләкләнде.

**III дәрәҗә лауреатлар:**

– Рузил Халиков «Моя история – Мой Татарстан!» эше өчен;

– Илмира Маштеева, Наилә Амячкина «Фотолетопись архива библиотеки» эше өчен.

Лауреатлар кәрәзле телефонга сертификат белән бүләкләнде.





**«В СИЛЕ КОЛЛЕКТИВА – НАШЕ БУДУЩЕЕ!» – «КӨЧЛЕ КОЛЛЕКТИВТА БЕЗНЕҢ КИЛӘЧӘГЕБЕЗ» НОМИНАЦИЯСЕ**

**I дәрәҗә лауреат:**

– Любовь Гарнизова «История развития дополнительного образования детей в Тетюшском районе» эше өчен.

**II дәрәҗә лауреат:**

– Гөлүсә Фәхруллина «Буыннарны тоташтыра китап: Чаллы китапханәләре тарихы» эше өчен.

**III дәрәҗә лауреат:**

– Нина Арисова «Листая страницы библиотечной истории» эше өчен.

Лауреатларга кыйммәтле призларга сертификатлар тапшырылды.

**«КРАЙ РОДНОЙ» – «ТУГАН ЯК» НОМИНАЦИЯСЕ**

**I дәрәҗә лауреатлар:**

– Ангелина Бәширова «Рождение эксклюзивного национального костюма через историю татарского народа» эше өчен;

– Милена Әбулханова «Казанская выставка культуры народов Востока» эше өчен;

– Альберт Гайнетдинов «Татар гөсләсе турында тарихи мәгълүмат» эше өчен.

Лауреатлар ноутбукка сертификат белән бүләкләнде.

**II дәрәҗә лауреат:**

– Артем Герасимов, Мария Шкляева «Татарская усадьба в селе Муслюмово. Традиции и современность» эше өчен;

– Алсу Фәтхетдинова «Тропами пионерии Чистопольского района» эше өчен;

– Мидхәт Газыймов «История деревни Кичу, Адамчи и Ерыкла тожъ» эше өчен.

Лауреатлар планшетка сертификат белән бүләкләнде.

**III дәрәҗә лауреатлар:**

– Алия Хәлилова «Туган ягым – Олы Нырсы» эше өчен;

– Гүзәл Рәхимова «Яңа Чәчкап авылы тарихы» эше өчен;

– Рушания Галәветдинова «Иске Иштерәк авылы тарихы».

Лауреатлар кәрәзле телефонга сертификатлар белән бүләкләнде.

Галина Лукоянова фоторәсемнәре








# БЕЗ ИТЕК БАСАБЫЗ

**(«Минем гаиләм» номинациясендә II дәрәҗә лауреат эше)**

**Газиз әткәсе фронтта һәлак булганнан соң, Нурислам (1937-2016) бабам – 13 яшьлек үсмер – өлкән агайларына ияреп, һөнәр үзләштерермен дип, авылдан чыгып китә. Чөнки өй тулы бала-чага, табында бер тәгам ризык юк… Ачлык сәфәргә кузгата малайны, кияргә киеме дә булмаганлыктан, Нурислам әнисенең ыштанын киеп, юлга чыга…**

«Шунда итекче һөнәрен үзләштерергә насыйп булды, – дип сөйләгән иде бабам. – Өйрәтсеннәр генә дип, ике ел абзыйлардан эш хакы да сорамадым. Нәрсә кушсалар, шуны үтәдем. Башта басарга өйрәндем, аннары башкасын да эшли башладым. Әмма итек ясауда иң авыры һәм иң мөһиме – түшәү. Түшәүче булу өчен зур сәләт һәм акыл кирәк. Тырыша торгач, анысына да өйрәндем».

Итекчелек белән кәсеп итә башлагач, Нурислам бабаем бик бәрәкәтле, хәерле, әйбәт һөнәргә өйрәнүен аңлый. Өйләнеп, үз балалары булгач, гаиләсен дә тәэмин итә. Кыш көннәрендә колхозда эш булмаганда, ике-өч кеше берләшеп, икешәр айга чыгып китеп, шактый гына акча эшлиләр. Күп еллар шулай йөри ул.

Туксанынчы елларда кризис башлангач, кешеләрнең күпме генә эшләп тә, хезмәт хакы ала алмыйча интегеп йөрүләрен күргәч, бабаем һөнәрен улына да өйрәтергә вакыт җиткәнлеген аңлый. Үзе дә заманында шул һөнәре ярдәмендә ачлыктан, ялангачлыктан котылган ләбаса. Алар аталы-уллы икәүләп, итек баса башлыйлар.

Әлбәттә, итек басу өчен йон кирәк. Ә йон булсын өчен сарык асрарга кирәк – күпләп сарык үрчетергә керешәләр.



Мөнир Шаһабиев



«Итек басуның хезмәте күп, – дия иде бабаем. – Башта йонны әйбәтләп эшкәртәбез. Сарык теләсә кайда йөри бит. Йонына тигәнәк, сырлан ябышып беткән булырга мөмкин. Машинага салганчы, йонны шул чүбеннән аралыйбыз. Аннары тетәбез һәм әкренләп түши башлыйбыз. Безнең бәләкәй өебез бар, шунда көйләнгән казаныбызны ягып җибәрәбез. Мөнир улым итекләр баса, ике-өч көн эшләгәнен мин җыеп манам. Махсус буяуларны Кукмарадан алып кайтабыз. Аннары бергәләп калыплыйбыз, киптерәбез, берләштерәбез һәм кешеләргә тәкъдим итәбез. Эшкәртә торган коралларын да үз кулларыбыз белән ясыйбыз. Эше күп булса да, җимеше затлы шул».

Чыннан да бабаемның куллары алтын. Ул курчак өе сыман күркәм йортны, каралты-кураларны хәләл хезмәте белән җиткергән.

Итек басу – гаиләбезнең бердәнбер шөгыле түгел. Без сыер, тана, бозаулар асрыйбыз, умарталарыбыз бар. Мал күп булгач, печәнне дә күп әзерләргә туры килә: чакыр-чокыр, елга буйларын чабабыз, кипкәч, алып кайтып өябез – шулай малларга азык җыела…

Хәзерге вакытта бабаем да, әбием дә – гүр ияләре инде. Әмма безгә биреп калдырган һөнәрләре исән. Әтием бик тырышып итек баса. Әйе, сүз дә юк, замана үзгәрә: киез итекләргә дә игътибар кимеде. Тик итекнең кадерен белгән кеше беркайчан да аннан баш тартмас.

Безнең гаиләдә бар малны хәләл көчен куеп табарга өйрәнгәннәр. Гаиләбезнең төп принциплары – хатын-кыз яисә ир-ат эшенә бүлмичә, барлык эшне күмәк башкару; гореф-гадәтләрне саклау; хезмәтне ярату. Сарык асрау, умартачылык белән шөгыльләнүдән





тыш, гаиләбезнең бабаем өйрәтеп калдырган үлмәс һөнәре бар – без итек басабыз.

**Дилә ШАҺАБИЕВА,**
**Саба, Кызыл Мишә авылы**

Автор фоторәсемнәре

# ХӘСИТӘ ФЕНОМЕНЫ

**Хәситә – татарларның этник төркемнәренә хас традицион бизәнү әйбере. Ювелир бизәкләр тезеп тегелгән буй тукыма сул як җилкәдән күкрәккә төшерелгән һәм уң кул астыннан үтеп, аркадан каптырылган. Мөгаен, бу күкрәк бәйләвече дини текстлар язылган амулет йөртү традициясенә барып тоташадыр – кечкенә кесә-капчыкка салынган бөти-догалар да буй тукымага яки тасмаларга беркетелеп җилкә аша асып йөртелгән. Тора-бара буй тукыма татар хатыны өчен затлы бизәнгеч булып киткән: аңа төрле талисманнар һәм аерым гына йөртелми торган бизәнү әйберләре беркетелгән. Хәситәләрне элеккерәк чорларда, мәсәлән, Казан ханлыгы ханымнары йөртүен без чамалап кына белә алабыз. Әйтик, XVII-XVIII йөз картиналары күчермәләреннән без Сөембикә ханбикәнең кыйммәтле күкрәк бәйләвече, түшелдерек йөртүен күрәбез.**

Хәситә фрагменты



XIX гасырның беренче яртысында хатын-кызның бәйләвеч йөртүен раслаучы үзенчәлекле документ булып, Карл Гунның рәсемнәре санала, алар Г.-Ф.Х. Паулиның «Народы России» альбомында (1862) литография буларак кулланылган. Күрәсең, хәситәне хәлле гаиләләрдәге хатыннар гына йөрткәндер, һәрхәлдә аның бәясенә Каюм Насыйри да игътибар иткән. «Янә кия хәситә дигән нәрсә; иңбашыннан китереп култык астыннан бәйли; кыйммәт төшә; бик яхшы булса йөз тәңкә тора», – дип язган ул. Үзенчәлекле бу бизәнү әйберен «үтеп барышлый» гына булса да, татар костюмын тасвирлаган бер генә автор да искәртми калмаган.

Күкрәк бәйләвече атамасының килеп чыгышын ачыкларга тырышып карасак, кызыклы нәтиҗәләргә юлыгабыз. Хәситә мөгаен үзенең татарча атамасын «касыйдә» дигән гарәп сүзеннән алгандыр. Касыйдә – күренекле тарихи затларның эш-гамәлләрен яки нинди дә булса тантаналы вакыйга-күренешләрне чиктән тыш мактап, олылап язган шигырь. Кайбер тел белгечләре фикеренчә, Болгар чоры традициясе турында сүз бара – яшь кызлар үзләренә багышлап язылган шигъри юлларны баш киеменә яки чәчүргечкә беркетелгән махсус күн яки металл футлярларда саклаган[1]. Әмма без хәситәнең функциясен хатын-кызны явыз рухлардан саклауга бәйләп карыйбыз, башка бизәнү әйберләре кебек, хәситә дә саклагыч ролен үтәгәндер. Карл Фукс та «бай сәүдәгәрләр йортындагы» хатын-кызларның киемнәрен тасвирлаганда хәситәнең шушы функциясен билгеләп үткән, энҗе-мәрҗәннәр белән бизәлгән, сул җилкә аша салынган бәйләвеч (бөти) һәм аның уң ягындагы кесәсендә догалар салынганын язган[2]. Бу контекстта хәситә атамасы мөселман диненең поэтик традициясе үрнәге булган Касыйдә әл-Бурда[3] әсәре белән бәйлелеге күзаллана. Сәет әл-Бусириның (1212-1294) Пәйгамбәрне зурлап язган поэмасы мөселман дөньясында гаять популяр булган, кешеләр аның могҗизаи көченә ышанган, поэма юллары белән җәмәгать йортлары бизәлгән, Мәүлет бәйрәмнәрендә көйләп укылган. Поэма күп телләргә, шул исәптән, төрки телгә дә тәрҗемә ителгән. Аның шигъри

**Хәситә. XIX гасыр. А.Ф. Лихачев коллекциясеннән**





**Хәситә. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы.**
**1923 елгы Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсенең Күргәзмә комитетыннан**

**Хәситә. XIX гасыр. Л.О. Сиклер коллекциясеннән**



юлларын, Коръән сүрәләре белән бергә, бөти итеп йөрткәннәр.

Шулай итеп, иңбаш бәйләвеченә тегелгән кесәдә яки ювелир футлярда саклагыч бөтиләр, еш кына әл-Бусири касыйдәләре фрагментлары язылган кәгазьләр сакланган. Вакытлар үтү белән әлеге исем хәситә рәвешендә традицион бизәнгечкә берегеп калган. Бу традиция Казан татарлары белән генә чикләнмичә, Кырым татарлары «сач-хасиде» – чәч толымнарына беркетелгән футляр йөрткән[4].

Татарстан Республикасы Милли музеенда сакланган хәситәләр коллекциясендә әлеге бизәнү әйберләренең балалар бәйләвечләреннән башлап, тәңкәләр, ялтыравык парча тасмалар, ташлар һәм асылмалы бизәкләр тыгызлап тутырылган авыр хәситәләргә кадәр төрле вариантлары бар. Тукымага Россия, төрек, фарсы, Европа вак акчалары тегелгән үрнәкләр дә саклана. Леон Сиклер тарафыннан тупланган татар бизәнү әйберләре коллекциясендәге күкрәк бәйләвечен хәзер Татарстан Республикасы Милли музееның «Алтын хәзинә» экспозициясендә күреп була. Республиканың Үзәк музеена 1922 елда Шәрыкъ халыклары музее коллекциясе белән бергә килеп эләккән бәйләвечне татар зәркәнчелек сәнгатенең үзенчәлекле анталогиясе диярргә ярый. Биредә татар осталары кулланган техник һәм стилистик алымнарны күзалларга мөмкинлек биргән күп төрле бизәнү әйберләре урын алган. Әлеге сәнгать әсәренең авырлыгы гына да 600 граммнан артык.

Башка үрнәкләре кебек үк, бәйләвеч ярымай формасындагы сары тукымадан булып, чит-читләренә көмеш парчадан тасма тегелгән. Тукыманың һәм парчаның төсе очраклы түгел – алтын һәм көмеш тәңкәләр тагын да ялтырасын өчен шушы төсләр сайланган.

Ярымайның эчке ягы 38 филигрань тәңкәле чылбыр белән бизәлгән. Чылбыр аерым бизәнү әйбере булгандыр, бәлки, XIX гасыр фотосурәтләрендәгечә, аңа асылма бизәкләр дә эленгәндер. Бәйләвечнең төп өлешен догалыклар һәм башка дини текстлар салынган кызыл бәрхет кесә алып тора – ул яка чылбыры дип аталган нәзакәтле каптырма куелган алтынланган тасма белән бизәлгән. Әлеге борынгы каптырма гаять кечкенә, барлык элементлары йомры һәм вак фирүзә ташлар сибелгән. Каптырма яшь кыз күлмәгеннән дип фаразларга мөмкин.

Бәйләвечнең аскы өлешенә җиде эре зәркән тәңкә тагылган, аның бишесе металлга бизәк сугып ясалган һәм төсле ташлар белән бизәлгән. Болар сыйфатлы ясалган гаҗәеп матур зәркән үрнәкләре. Андый тәңкәләр, бәйләвечкә кую өчен, зәркән осталарыннан махсус ясатып алынган һәм иясенә төрле вакыйгалар уңаеннан бүләк ителгән, әйтик, бала туу хөрмәтенә.

Бәйләвечнең урта рәтенә ваграк тәңкәләр тезелгән. Түгәрәк, озынча, ромб рәвешле яки сигез почмаклы җиз тәңкәләргә перламутр, кызгылт сердолик, тонык яшькелт паста, үтә күренмәле саргылт хризопраз, вак фирүзә, кара агат

**Хәситә. XIX гасырның икенче яртысы.**
**А.Ф. Лихачев коллекциясеннән**





**Бөтиле һәм амулетлы балалар күкрәк бәйләвече.**
**XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы**

кашлар кертелгән. Алар арасына һәм өске регистрга шарсыман төймәләр һәм тамчысыман асылмалар, вак акчага охшаш җиз тәңкәләр, овал сердоликтан җыйнак кына каптырмалар тегелгән. Яка каптырмасы һәм чулпыларның алтын йөгертелгән детальләре – кашлы җиз тәңкә, ярымай формасындагы «көянтәчекләр», асылма фрагментлары аеруча кыйммәтле булып күренә.

Парчадан тегелгән ике хәситә А.Ф. Лихачев коллекциясеннән. Аларның берсе позументтан ясалган зур кесәле, кесәсенә салынган догалыклар әле дә саклана. Чылбырлар һәм җиз тәңкәләр белән бергә биредә күп төрле предметлар бар – перламутр кабырчыклар, эре коралл сәйләннәр һәм табигый коралл кисәкчекләре хәситәнең саклаучы функциясен арттыра. Сөңге очын хәтерләткән сердолик сәйләннәрнең өсте буразналанган – болар Урта гасырның Якын Көнчыгыш муенсаларына хас бик борынгы амулетлар. Көмеш кысалы агат һәм сердоликларның да бик борынгы булуы күренә.

Саклагычлар һәм амулетлар белән бизәлгән балалар хәситәсе дә бар – аны берничә буын баласы тагып йөрткәндер, күрәсең, эчке тукымасы кат-кат тегелгән, кара бәрхет нигезенең дә төзәтелгәнлеге күренеп тора. Кырыенда догалар салынган дүрт бәрхет кесәсе бар, алар янәшәсендә – борынгы тотем саклагыч – көмеш кысага утыртылган селәүсен тырнагы. Хәситәнең башка элементлары – сәдәфләр, агач кисәкләре, төсле пыялалы һәм фирүзәле тәңкәләр кызыл һәм сары йон җепләре белән тегелгән, болар барысы да күз тиюдән саклау билгесе, чуар ялтыравыклар явыз көчләрнең игътибарын юнәлтә дип ышанганнар.

Безнең коллекциядәге һәр бәйләвеч татар хәситәсе дип аталган кызыклы һәм күпкырлы феноменны аңларга булышачак, дисәм бер дә арттыру булмас кебек.

**Лилия САТТАРОВА,**
**сәнгать белгече, Татарстан Республикасы**
**Милли музееның тупланмалар буенча**
**җаваплы генераль директор урынбасары**

Фоторәсемнәр Татарстан Республикасы
Милли музееннан

Чыганаклар:

[1] Миллият сүзлеге: Аңлатмалы сүзлек / Төз.-авт. А. Тимергалин. – Казан: Мәгариф, 2007. – Б. 231, 521.
[2] Фукс К.Ф. Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях. – Казань, 1844.
[3] Бурда / Ислам. Энциклопедический словарь. – М.: Наука, 1991. – С. 44.
[4] Рославцева Л.И. Одежда крымских татар конца XVIII – начала XIX в. Историко-этнографическое исследование. – М., Наука, 2000. – С. 42.

# Бергәләп бизибез!









**Информант Мөхлисә Билалова Л.Х. Мөхәммәтҗановага татарларда кыз елату йоласы турында сөйләү вакытында. Чиләбе өлкәсе Похвистнево районы Нугай авылы. 2016 ел**

# ЕЛАП БАРСАҢ, КӨЛЕП ЯШӘРСЕҢМЕ
## яки рухи мирасыбызда сыктаулар

**Сыктаулар – халык авыз иҗатының игътибарга лаек кызыклы күренеше. Әйтәсе фикерне җырга салып, елап-сыктап башкарудан гыйбарәт бу төр шигърият төрки халыкларның дастаннарында сакланып калган. Болар – хушлашу, читкә китү яисә герой үлеменә бәйле җыр белән сыктап әйтелгән тезмәләр. Әйтик, «Айсул улы Әхмәт», «Копланды батыр», «Мамай», «Адел солтан», «Эр Күсеп», «Елкилдек батыр» һәм башка дастаннарның һәркайсында каһарман үлеме белән бәйле елау-сыктау монологы бар. Копланды үлеменнән соң хатыны Карлыгач, Адел солтан үлгәннән соң Данабикә, Мамай үлгәч, җыручы-автор, Күсеп үлгәч, хатыны Акмаңгай елап әйткән сүзләр тыңлаучыны әсир итә. Бу – традицион эпоста чичән тарафыннан кулланыла торган отышлы алымнарның берсе.**

Чура батырга багышланган дастаннарда, аның һәлакәтеннән соң анасы Миңлесылуның елавы да – төрки эпос өчен типик әлеге күренешнең ачык үрнәге:

*Ай, ай, көнем, ай, көнем,*
*Җаным, бәгърем, Чура улым,*
*Суга баткан, бел, улым.*
*Кайгылар, сөенечләрең*
*Истән китмәс үк булдың,*
*Инде нәрсә әйтәем?*
*Баласы үлгән дөядәй,*
*Бызлый-бызлый китәем.*

Тыңлаучыга эмоциональ тәэсир итүгә корылган мондый тәэсирле урыннар татар эпосында тора-бара актуальлеген җуя төшкән: кыскаруга йөз тоткан яисә бөтенләй төшеп үк калган. Моның сәбәпләре кайчандыр йолага бәйле башкарыла килгән күләмле эпик әсәрнең йоладан аерылып, мөстәкыйль жанрга әверелүе, кульязма һәм басма китап чорында исә китабилашуы һәм башкага бәйле. Ә менә халыкның йола фольклорында исә елау-сыктау эпизодлары әле бүгенге көндә дә очрый. Алай гына да түгел, туй-йола поэзиясендә бу төр иҗатның чагыштырмача актив рәвештә «тере» башкаруда бүгенгәчә яшәп килгән очраклары бар.

Туй йоласында ире йортына китәр алдыннан кәләшне махсус елатуга юнәлдерелгән җырлар күп. Бу җырлар драматик табигатьле, алар йола комплексында билгеле бер гамәлләр кылу (акциональлек), ягъни тамашалылык аша тормышка ашырыла. Туй йоласындагы сыктау җырлары гадәттә монологка яисә диалогка корылган була. Аларда туй алдыннан кыз гаиләсендәге үзара мөнәсәбәтләр, кияүгә китүче кызның күңел халәте, язмышка карата моң-зарлары, үпкә-борчылулары тасвирлана. Бу төр җырларда кавышу, мәхәббәт һәм башкага бәйле шатлык, сөенеч кебек уңай хисләр берничек тә чагылыш тапмый. Йола татарлар яши торган төрле төбәкләрдә төрлечә аталып йөри: «таң кучат» (ягъни таң әтәче), «кыз елату», «чеңләү» яисә «чеңләтү», «әтеки әйтерү». Төрлечә аталуына карамастан, боларның барысының да нигезендә туй алдыннан кәләшнең сыктаулары ята.

Татарлардагы «кыз елату» йоласының тамырлары бик тирәннән килә, төрки халыкларның мифологик фикерләвенә үк барып тоташа. Бик элекке, әле исламга кадәрге үк иртә чор-

Туй йолалары – өйләнешү кагыйдәләре, туй гореф-гадәтләре. Үткән заманнарда татар халкына яучылап-димләп өйләнешү хас булган. Егетнең туганнары кызны кияүгә сорап аның әти-әнисенә яучы җибәрә. Яучы кызны кияүгә бирергә күндерә, өйләнешү шартларын (калым күләмен, туй вакытын һәм башкаларны) ачыклый. Аннан кыз ярәшү һәм килешү йолалары башланып китә. Әлеге йолалардан соң ике якның бүләкләр алмашуы һәм туганнар белән аралашу мәҗлесе үткәрелә. Төп туй йолалары калымның бер өлеше түләнгәч, кыз йортында уздырыла: шәригать кушканча никах укыла һәм никах мәҗлесе үткәрелә. Никах мәҗлесендә кияү белән кәләш катнашмый, алар урынына әти-әниләре генә була. Никах мәҗлесе берничә көн дәвам итә, кәләшнең туганнары кияүнең туганнарын чиратлашып кунак итәләр. Казан татарларында ир-атлар һәм хатын-кызлар мәҗлесе аерым уздырыла. Никах мәҗлесе тәмамлангач кына, кияү беренче тапкыр кыз янына керә. Кәләшнең ахирәтләре кияү егетен яхшылап күздән кичерәләр, шаян сынаулар үткәрәләр, аннары кияү келәтенә озатып куялар. Кыз йортында кияү дүрт көн кунак була, кәләшнең туганнарына бүләкләр өләшә (никах түшәге, яшь килен мунчасы һәм башкалар өчен йолым түли). Иң кыйммәтле бүләкне хатынына тапшыра. Кияү бүләкләренә каршы яшь килен үзе тукыган-чиккән бүләкләрне бирә. Шул рәвешле «кияүләп йөрү» башланып китә: кияү атнага 1 тапкыр (һәр атнакич) кәләше янына килеп йөри, әлеге йөрүләр йолым түләнеп беткәнче дәвам итә. Зур туй яшь киленнең кияү йортына төшүе һәм кияү туганнарында туй мәҗлесләре уздыру белән тәмамлана. Киленне каршы алганда аның аяк астына мендәр яки эче тышка әйләндерелгән тун салалар, кулларын онга батыралар, балмай каптыралар, нинди дә булса терлек бүләк итәләр, су юлын күрсәтәләр. Киленнең үзе чиккән, тукыган әйберләре белән өйне бизәү килен багу йоласына кергән. Керәшен татарларының туй йолаларындагы кайбер аерымлыклар (мәсәлән, чиркәүдә никахлашу) христиан дине канунннары белән бәйле. Татар халкында ябышып чыгу яисә кыз урлау сирәк хәл очраган. Җәмәгатьчелек андый юл белән өйләнешүне хупламаган.

**Татар энциклопедия сүзлеге /**
**Баш мөхәррир М.Х. Хәсәнев;**
**җаваплы мөхәррир Г.С. Сабирҗанов. – Казан:**
**ТР ФА Татар энциклопедиясе институты,**
**2002. – 830 б.: ил.**

ларда теге яки бу күренешләр турында мифик күзаллаулар яшәп килгән, бу күзаллауларда «теге» һәм «бу» дөнья сюжеты гаять популяр булган, тереләр белән параллель үлеләр дөньясы да бар, үлгәннән соң кеше бу дөньядан икенчесенә күчә дип саналган. Буй җиткән кызның атасы гаиләсеннән кияү йортына китүе дә бер дөньядан икенчесенә күчүгә, ягъни үлемгә тиңләнгән, шуңа да кызның елап китүе табигый саналып, аны елатып озату хупланган:

*Өстемдәге кизеле күлмәгемнең*
*Итәгенә комач бәйләдем.*
*Бәлки бу хәлләрне күрмәс идем,*
*Юкка олан чакта үлмәдем.*

Исламга кадәр үк ныгып урнашкан бу йола кызның туган йортында кала торган «ияләр»нең ачуын кузгатмас өчен башкарылган булырга да мөмкин. Елауларны, хәсрәтләрне «бу дөнья»да калдырып, ир йортындагы «икенче дөнья»га елмаеп барып керү дөрес саналган. «Үз атаң йортында елап бетермәсәң, биата йортында кан-яшь түгәрсең» дигән ышану булган. «Кыз елату» йоласы яисә аның кайбер элементларының бераз үзгәргәнрәк мотивациядә әле хәзерге көндә дә яшәве әһәмиятле.

Иртәгә кияү йортына китәсе дигән көнне кәләш, таң әтәчләре белән үк уянып, сыктый башлый торган булган, җырларның эчтәлеге аның кыз чагын сагынуы, бүгенге хәленә кызгану хисләре уяту белән сугарылган.

*Таң-таң ата микән, әй, юк микән?*
*Таңның йолдызлары бар микән?*
*Таң-таң атмас борын мин елыймын,*
*Мине аяучылар бар микән?*

Мондый монолог-җырларда кыз еш кына үзенең атасына, анасына, агаларына, дус кызларына мөрәҗәгать итә. Менә, мәсәлән, анасына, аннары дусларына ул болай ди:

*Ябалак та, ябалак кар явадыр,*
*Палуна (диал.: утын әрдәнәсе. – Л.М.) башларын сылыйдыр.*
*Торчы, әни кабәм, уянчы,*
*Язулы яшь балаң елыйдыр.*

Яисә дус кызларына багышлап сыктый:

*Торыгыз тиңнәрем, маем, торыгыз*
*Миңа кычкырыгыз «таң кучат».*
*Таңдый зарялардан елыйбыз,*
*Бәхетле булыйк дип телибез.*

Сыктауларын әкрен генә «елап» башлаган кызның тавышы көчәя барып, алга таба ул тагын да катырак сыктый башлый:

*Ишеккәем кинәт ачылды,*
*Зынҗырлары җиргә чәчелде,*
*Сөйләшкән көннәрем җиткәчтен,*
*Татлы йокыларым ачылды.*

Алдан әзерләнеп килгән дус кызлары, зур яулык астына барысы бергә кереп, яисә ачык тәрәзә аша кызның җырларын эләктереп ала торалар, кушылып җырлыйлар яки җырны үзләре башлап, кыз да аларга кушыла:

*Куштым кара шәлләр алырга,*
*Кайгыдан башыма ябарга,*
*Мине яшьләй ят кулына биреп,*
*Терелләй куясыз каберга.*

Бик борынгы чорда чит гаиләгә китү үлемгә тиңләнсә, соңгырак чорларда хәл уңай төсмер алмаган, кияүгә бирелә торган кызның чит гаиләдәге язмышы шактый ачы булу тәҗрибәсе «кыз елату» җырларының моңсу эчтәлеген үзгәрешсез калдырган. «Чит» җирдә, ягъни кыз барасы гаиләдә булачак тормыш бик авыр, ә гаилә әгъзалары барысы да «мәрхәмәтсез» дип күз алдына китерелгән. Килен сыйфатында гаиләгә яңа килеп кергән хатын-кызга төрлечә кимсетеп караулар, әлбәттә, булган. «Килен кеше – ким кеше, алабайга тиң кеше» мисалындагы кебек мәкаль-әйтемнәрнең халыкта киң таралганлыгы да моны раслый. Шуңа да китәсе кызның үзе үскән гаиләсенә әйтәсе «үпкәләре» шактый, ул атасын, агасын, җиңгәсен аны, бу гаиләдә артык кашык санап, тизрәк кияүгә бирүдә гаепли:

*Безнең артыбызда кызыл гөл,*
*Абзыкаем әйтә гөл түгел.*
*Җиңгәкәем шулай әйтәдер,*
*Кызлар ашатырдай ел түгел.*
*Катлама казанын элдегез,*
*Кайнамасмы диеп белдегез?*
*Бигрәк тә яшьли бирдегез,*
*Ахры китмәс диеп белдегез.*

«Кыз елату» йоласында кызның дусларыннан тыш та кешеләр катнашкан. Арада йолага махсус чакырылган оста чеңләтүчеләр булган. Кызны түрдә урындыкка утыртканнар, дүрт почмагын дүрт яктан тотып, баш өстендә киң яулык тотып торганнар. Шушындый күренеш астында билгеле бер көйгә ямансу һәм кызганыч эчтәлектәге җыр-сыктаулар башкарылган:

*Саулармы сез, абыстакайлар,*
*Кызны елатырга килдек без,*
*Елатырга түгел, еларга,*
*Бергә елашырга килдек без.*
*Аран алдыннан кош уза,*
*Уң аягында кургашын.*
*Сокланмагыз, дуслар, бай кәләшкә,*
*Җан кунардай булсын юлдашың.*
*Биек кенә тауның башында*
*Әллә яңгыр, әллә кар микән?*
*Әрнеп кенә сызлап елыймын,*
*Миннән язулырак бар микән?*
*Йөгереп кенә кердем өйләргә,*
*Әнекәем белен пешерә,*
*Нигә күңел генәм сынык минем –*
*Үз тиңнәрем түгел төшәргә.*

Кияүгә китәсе кыз елаган, аңа кушылып, башкалар да күз яше түгеп алганнар. Кызны елату соңгырак чорларда аны туй киемнәренә киендерү белән параллель башкарылган. Яулык астына ирләрне кертмәгәннәр. Йоланың трансформацияләнүе шартларында исә бу тәртипләр үтәлеп бетмәгән очраклар да бар. Әйтик, XXI йөз башында Татарстанның көньяк-көнчыгыш районнарында (Мөслим, Минзәлә, Азнакай), Чиләбе өлкәсендә бу йоланы башкарганда яулык астына кызның атасын да кертүләре хакында сөйләделәр[1]. Бу йоланың төп максаты кызны елату булган, тора-бара бу максат «еламыйча китү яхшы түгел, кияүгә елап бару кирәк» дигән ышануга ук әверелгән. «Елап барсаң, елмаеп яшәрсең» дигән гыйбарәнең бүгенге көндә дә очравы шул хакта сөйли.

Кайбер якларда туй алдыннан башкарыла торган «кыз елату» җырларының бик озакка сузылуы билгеле. Әйтик, Мордва республикасында яшәүче татарларда унбишәр кич рәттән кыз елатулар булган[2].

Сыктауларның төп хасияте – трагизм. Татарларның туй йоласы фольклорында сакланып калган сыктауларның бай поэтикасы кыз өлешенә төшкән котылгысыз һәм җиңеп булмастай хәсрәтне гәүдәләндерә. Лиризм һәм драматизм белән сугарылган бу йоланың нигезендә борынгы ышанулар ята. Сакланып калган сыктау текстлары – гаилә-көнкүреш йола фольклорын сәнгати баета торган күренеш. Халыкның сүз сәнгатендә сыктаулар күптән инде үзенең беренчел мифологик билгеләрен югалтып, үзгәргән-трансформацияләнгән булсалар да, әле бүгенге көндә дә татарлар яши торган кайбер төбәкләрдә бу йоланың элементлары сакланып калган булу гореф-гадәтнең тирән тамырлары турында искәртә.

Ислам һәм башка факторлар тәэсирендә мәҗүсилек, моң һәм хис белән сугарылган «кыз елату» йоласы арткы планга кала барган, әмма бөтенләй үк юкка чыгып бетмәгән. Моның шулай булуы – рухи мирасыбызны барлау юнәлешендә яңа эзләнүләргә этәрә торган күренеш. Бүгенге көндә материалга тарихи-типологик якын килү халкыбыз йолаларының төрле ышанулар-мифлар белән бәйлелегенә чыгарга, сыктаулар табигатендәге борынгылык тамырларын ачыкларга ярдәм итә ала. Татар халкының сүз сәнгатендәге сыктауларда тормыш хәлләре, халыкның социаль омтылышлары, иҗтимагый таләпләре чагылыш тапкан. Бик борынгы заманнарда ук стихияле туган бу төр иҗат әсәрләренең эстетик әһәмияте югары. Шуңа өстәп, сыктаулар тарихыбыздагы аерым чорларны танып белергә, аңларга, бәяләргә дә ярдәм итә.

**Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,**
**филология фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты баш фәнни хезмәткәре**

Рөстәм Мөхәммәтшин фоторәсеме

Чыганаклар:

[1] Мөхәммәтҗанова Л.Х. Пар гына күкеләр чакырганда... (Чиләбе өлкәсе татарларында заманча фольклор) // Казан утлары. – № 3. – 2017. – Б. 138-145.
[2] Федянович Т.П. Семейные обряды в этнографической литературе // Семейные обряды мордвы. Труды. Вып. 76. Саранск: Морд. книж. Изд-во, 1984. – С. 3-76.

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ «ОСТАЗБИКӘ» ПОВЕСТЕНДӘГЕ ТУЙ ЙОЛАЛАРЫ



**Гаяз Исхакыйның кайсы гына әсәрен алып карасак та, аларда татар халкының гореф-гадәтләре, күптөрле ышанулары, бай милли традицияләре һәм йолалары урын алган. Әдип халык тормышын, тарихын, көнкүрешен яхшы белгән, детальләргә игътибарлы булган, һәр нәрсәне документаль төгәллек белән теркәп калдырырга тырышкан. Исхакый аеруча яратып һәм белеп тасвирлаган өлкәләренең берсе – ул гаилә кору белән бәйле никах-туй йолалары. Алар язучының бер әсәреннән икенчесенә күчә барып, бер-берсен тулыландыра. «Кияү» хикәясендә ата-ананың, булачак мулла-кияүгә ярыйм дип, артыгы белән тырышуы, «Сөннәтче бабай»ның яңа хатын алып тормышын көйләргә омтылуы, «Ул әле өйләнмәгән иде» әсәрендә дөрес гаилә кору хыялы белән яшәүче Шәмсетдин сурәтләнә.**

Барлык әсәрләрдә дә гаилә кору белән бәйле вакыйгалар кеше тормышының әһәмиятле, борылыш этабы буларак бәяләнә. Дөрес сайланган кеше белән корылган гаилә берәүләрне бәхетле итә, ә тормышыңны очраклы кеше белән бәйләү афәткә дә китерә ала, ди автор. Никах-туй йолаларын сурәтләү ягыннан иң бай әсәрләрнең берсе – «Остазбикә» повесте. Әсәрдә ике туй (остазбикәнең кияүгә чыгуы, соңыннан ирен икенче хатынга өйләндерүе) һәм алар арасындагы вакыйгалар, моңа бәйле төп герой Сәгыйдә остазбикәнең хис-кичерешләре тасвирлана.

Борынгыдан татарларда гаилә коруның беренче этабы яучы җибәрү була. Яучы – егет ягыннан кызны кияүгә димләүче, аны сорап килүче кеше. Аның төп вазыйфасы – ике якны үзара килештерү, ахыр чиктә берләштерү, шуңа күрә теләсә кем яучы булып бара алмый. Яучының сүзе үтемле, үзе ышанычлы, халык арасында яхшы даны таралган булырга тиеш.

Безнең әсәр дә нәкъ менә яучылыктан башланып китә. Хәзрәт кызы Сәгыйдә үсеп буйга җиткәч, аны кияүгә сорап, төрле яктан яучылар килә башлый: «Ул кыз булып үсеп килә башлагач та төрле йирләрдән мулла, мөәзингә, мулла сыманрак булырга тырышкан байларга сорарга тотындылар». Яше җиткән кыз баланы вакытында «урнаштыру» – ата-ананың изге бурычы. Сәгыйдәнең әтисе дә бу мәсьәләгә бик аңлы якын килә. Ул теләсә-кем белән туганлык җепләрен бәйләргә ашыкмый, кызы егермесен тутырып килсә дә уңай җавабын кичектереп, туры килердәй «кандидат»ны көтә. Ниһаять андый кеше табыла: «Еракта гына булса да, яңа указ алган бер муллага Сәгыйдәне сорарга килделәр».

Кызны бирергә риза булган очракта да ата-ана беренче килгәндә үк яучыга соңгы сүзен әйтми, каршы килмәячәкләрен генә сиздерә. Бу да йола буенча эшләнә. Каршы очракта мондыйрак җаваплар әйтелә: «Кызыбыз яшь», «Быел туй итү мөмкинлегебез юк». Ә менә: «Киңәшербез», – дигән җавап яучыларның икенче тапкыр килергә тиеш булуларын белдерә: «Ләкин хәзрәт үзе кияү булачак шәкертне... бер мәртәбә күреп, ихлас баглаганга, «киңәш итешик» дигән җавапны бирдертте».

Татар халкында булачак кияү яки киләш турында мәгълүмат җыю, аны яхшырак белергә омтылу гадәте булган. Бу юлыда да: «...баш-

кода булып килгән Фәхри мөәзин артыннан ук, абыстайның туган кардәшен ат җиткереп шул авылга «югалган атны эзләргә» йибәрделәр» һәм ул «...кияү булачак мулланы, атасын, мәхәлләсен белергә керешә». Кызны кияүгә дөрес җиргә урнаштыру җитди мәсьәлә булараk кабул ителгән, башка туганнар да бу җаваплы эшне хәл итүдә катнашканнар: «...бөтен кардәш-кабиләне җыеп... карар чыгарылды». Ниһаять булачак кияү, аның гаиләсе турында мәгълүмат туплангач, өйләнешү турында шартлар сөйләшенә. Хәзрәт яшь гаиләнең аерым яшәүләрен, кызның каенана йортында хезмәтче ролендә йөрмәячәген таләп итә.

Моннан соң булачак кодалар белән танышырга дип кияүнең ата-анасы кыз йортына килә. Сәгыйдә бу вакыт кечкенә өйдә утыра. Булачак каенатасы белән каенанасын ул ярыктан гына күреп ала һәм шунда ук кызның күңелен тирән борчу баса: аларның кыяфәтләре, сөйләшүләре, рәвешләре тупас булып тоела. Бераздан, чәйләп, аралашып алганнан соң, аны «каенанага күрендерергә» алып чыгалар, күрешеп, дога укыйлар һәм үзара бүләк алышалар: кыз каенанасына сигез чиреклe ефәк яулык, ә каенанасы аңа ике талир тәңкә бирә. Сәгыйдәнең тирән кайгыга батканын күреп, атасы хәзрәт туйны туктату ягын сөйләргә тотына, гәрчә бу адым халык арасында зур шау-шу куптарыр иде. Чынлап та, никахның шартларының берсе – кызның кияүгә риза булып баруы.

Кешенең нинди икәнен белергә теләсәң, аның гаиләсенә, үскән нигезенә карарга кирәк, диләр. Ләкин шул ук вакытта Исхакый ата-ананы сайлап тумыйлар, һәркем үз тормышы һәм гамәлләре өчен үзе җаваплы дигән фикерне дә белдерә. Булачак кияү, яшь мулла Габделвахид та ата-анасына охшамаган булып чыга: «Боларның мужик икәнен бит без үземез дә белдек. Угыллары охшамаган, ди. Казан шәкерте, ди».

Сәгыйдә үз ризалыгын биргәч, никах көне килеп җитә. Никах мәҗлесе кыз йортында уза. Кияү үзе мәҗлестә юк, аның ата-анасы гына катнаша. Кода-кодагыйларны сыйлыйлар, бүләкләр алышалар, аларны озаткач кына, кияүне китерәләр. Кыңгырау тагылган атлар якынлашкан саен, яшь хатын кияү килгәнен ишетеп, борчылып тора. Ләкин кияүне күрүгә аның өстеннән авыр бер йөк төшә, борчулары да онытыла.

Никахтан соң кияүлек вакыты – бикәчләү башлана. Бу – кияүнең никахтан соң, киленне үз өенә алып кайтканга кадәр, кыз янына килеп йөрү чоры. Кыз ата-ана йортында яшәвен дәвам итә, ә кияү, ата-ана шарты буенча, туйга кадәр мал-мөлкәт туплый, әзерлек эшләрен башкара. Туйлар, гадәттә, көзге эшләр, сугымнар тәмамлангач уза.

Шул рәвешле яшьләр өйләнешә. Гаяз Исхакый дөрес итеп, фикерләшеп корылган гаилә бәрәкәт чыганагы икәнен ассызыклый. Габделвахид мулла белән Сәгыйдә остазбикә шактый мул тормышта яши, авыл халкы аларны хөрмәт итә. Тик остазбикәне балалары булмау борчый. Ул үзе өчен дә бик авыр булган, ләкин аны тагы да бөеклеккә күтәргән карар кабул итә: унике ел гомер иткән хәзрәтен өйләндерергә, үз өстенә көндәш алырга ниятли.

Шул рәвешле Сәгыйдәнең тормышында икенче тапкыр туй мәшәкатьләре башлана. Бу юлы туйга әзерлек кияү йортында бара. Сәгыйдә иренә хатынны үзе сайлый, үзенең укучысы Галимәне сорарга яучы булып та үзе бара. Әлеге туйга остазбикә бик җаваплы әзерләнә: «Ул шул ук кәеф белән туй ашлары пешерде. Аларның яхшы булып уңуы өчен шулай ук тырышты». Һәркемгә тиешле бүләкне, барлык кирәк-яракларны ала. Туйда бүләк бирешү, якыннарның күңелен күрү – якыннарның уңай теләген ишетү, араларны ныгытып кую билгесе дә ул. Кияү озатуны карарга дип бала-чага җыела, аларга да тиешле бүләкләр бирелә. Икенче көнне иртүк кияү чәенә кунаклар чакырыла. Алар арасында иң хөрмәтле кунак, әлбәттә, Сәгыйдә остазбикә була. Гаилә нигезен, киләчәк буынны саклап калу өчен Сәгыйдә үз хыялына, йөрәк әрнүе, көнләшү хисләренә карамыйча иреша. Автор әйткәнчә: «салкынлыгын югалтмый», һәр эшне уйлап, үлчәп башкара.

Милләт язмышын кайгырткан Гаяз Исхакый, бер яктан, халыкның төп рухи кыйммәтләреннән булган йолаларны үзенең әсәрләрендә җыйнап куя, ә икенче яктан шушы йолаларга таянып иҗат ителгән төрле сюжетлар ярдәмендә бәхетле гаилә моделен күрсәтергә омтыла. «Остазбикә» повесте – моның күркәм үрнәге.

**Эльза НӘБИУЛЛИНА,**
**Татарстан Фәннәр академиясенең**
**Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм**
**сәнгать институты аспиранты**

# «...ЯУЧЫЛАГАН КЫЗЫБЫЗНЫ АЛМЫЙ КАЛЫР ДИМӘГЕЗ»

**Татар театрында туй йолаларына басым ясалып махсус язылган пьеса буенча куелган спектакль бар. Бу ике легендар шәхес – Туфан Миңнуллин белән Марсель Сәлимҗанов тандемыннан туган «Гөргөри кияүләре» спектакле. Спектакльнең премьерасы Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында 1995 елның 21 маенда булган.**

Керәшен татарлары фольклорына нигезләнгән бу җырлы-биюле тамаша Камал театрының иң популяр спектакльләренең берсе.

Сюжеты: Гөргөри абзый һәм Кәтернә түтинең төпчек кызлары Үринәне берьюлы өч егет яратып йөри. Олы кызлары икесе дә атасыз бала үстерә. Шуңа күрә Гөргөри абзый Үринәне керәшен татарлары йолалары буенча гына кияүгә бирергә карар кыла. Шуннан китә кыз йортына яучы җибәрүләр, бил алышулар, җыр-бию белән сынашулар.

Спектакльдә йолаларны саклаучы керәшен карчыклары – Палый белән Әүдәки рольләрен озак еллар дәвамында Вера Минкина белән Нәҗибә Ихсанова уйнады.

«Әти «Гөргөри кияүләре» пьесасын язу өчен Лаеш районының Ташкирмән дигән керәшен авылында Коля дәдәй белән Кәтернә түтәйләрдә яшәде. Йолалар турында шул авыл кешеләреннән сорашкандыр инде. Пьесаның персонажлары да шул авыл кешеләренә охшатылган, танып әйтүчеләр дә булды. Әлбәттә, керәшен фольклоры буенча Геннадий Макаров, Галина Казанцевалар белән сөйләшкәндер», – ди Туфан Миңнуллинның кызы Әлфия Миңнуллина.



**«Гөргери кияүләре» спектакленнән күренеш.**
**Рольләрдә: сулдан – Россиянең һәм Татарстанның халык артисткасы Вера Минкина, Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисткасы Дания Нуруллина, Россиянең һәм Татарстанның халык артисткасы Нәҗибә Ихсанова**

Фоторәсем Н. Ихсанованың «Уйнап узган гомер» китабыннан алынды



# МИЛЛИ ТУЙЛАРНЫ ТАТАРСТАНДА НИКАХЛАР САКЛЫЙ

**Туксанынчы елларда милли үзаң үсеше милли йолаларны кайтарды. Аларның күтәрелеп китүе Кама аръягыннан башлап, Уфага кадәрге арада барды. Чөнки биредә туган телебезне, моңны, массачыл мәдәниятне саклаучы төбәк. Кама аръягы модасы әкренләп Казан артына да килде – табыннарда эре бавырсаклар пәйда булды, иң матур гадәт булып, туганлашасы ике як арасында яулык, түбәтәй алмашу китте. Бу милли җанлы кешеләр яшәгән Чаллыда, Түбән Камада башланып, бөтен Татарстанга таралды. Хәзер Казан артында да кияүгә чыгучы кыз булачак иренең әти-әнисенә яулык белән түбәтәй алып килә. Кыз сорарга баручы егет тә булачак кода белән кодагыйга түбәтәй белән яулык алып бара.**

Милли туйларны, гореф-гадәтләрне Татарстанда никахлар саклый. Никах мәҗлесендә татар җыры да, биюе дә, татар теле дә, милли киеме дә була. Иң мөһиме, түбәтәй киелә, кайбер затлы ханымнар калфак та кия. Бу инде никахның милли туй булып үсеп чыкканын күрсәтә.

Минемчә, чын милли туй ул – татар телле туй. Табын янында гармунга җырлашып утырулар, өстәлдәге милли ризыклар – болар татарлыкны шактый искәртеп тора. Мәсәлән, токмачлы аш, итле бәрәңге, сөтле, күрәгәле чәй, чәк-чәк, бавырсак, каклаган, пешкән каз-үрдәк, сарык итеннән һәм аеруча ат итеннән пешерелгән милли ризыклар, казылык.

Милли йолалар төбәкләргә, районнарга да бәйле. Ульянның кайбер авылларында туй йолаларының үз тәртибе бар. Ике кат баш кодалый киләләр – берсендә сөйләшеп, икенчесендә яхшы сүз алып китәләр. Аннары кыз алу – кыз өендә мәҗлес, икенче көнне егет өендә «ижап кабул» дип атала торган дини мәҗлес үтә. Өченче көнне егет өендә килен күрсәтү яки килен чәе була. Егетнең туган-тумачасы җыелып килен белән таныша.

Зур туй алдыннан «чебелдек печү», «сый», «сый кайтару», «придан төшерү», «кодалар чакырышу», «ызба киендерү», «өй күрсәтү» кебек йолалар уздырыла. Аннары «яшьләр туе (язылышу)» була, артыннан «арчи», «дөм-



бер» һәм башкалар оештырыла. Хәллерәк гаиләләрдә туйлар шулай ай буе бара иде.

Элегрәк туйлар Ташкент якларында затлы, купшы, күп кеше чакырып, артистлар белән рестораннарда яисә кафеларда уза иде. Аннан ул гадәт Татарстанга да кайтты. Бездә ул 20 еллап дәвам итте дә, хәзер сүрелә башлады.

Башкортстан татарларында, туй йоласы буларак, күп итеп акча салу һәм акчага сату гадәте бар. Мәсәлән, чәк-чәк чыга, кунаклар акча салалар да кабып карыйлар. Оренбург якларында җырлаган кеше өстенә кәгазь акча сибәләр – бу казахлардан кергән гадәт.

Кама аръягыннан алып Уфага кадәрге аралыкта туйга бавырсак, чәк-чәк, каз алып килү киң таралган. Әмма парлап алып килү мәҗбүри түгел. Казан арты татарларында исә парлы чәк-чәк, парлы каз күтәреп киләләр. Җиде пар ризык китерү дә бар: мәсәлән, парлы пар каз, парлы үрдәк, парлы конфет, бал, чәй, бәлеш, калач.

Ступай чумары – Шыгырдан татарларында сакланган. Ступай – милли мәҗлесләрнең берсе. Анда кыз һәм егет ягында өчәр көн туй уза, үзара бүләк алышулар була. Элек Шыгырданда бәрәкәт килә дип, туйларны өйдә ясыйлар иде. Хәзер анда да кафеларга күчә башлады.

Себер татарларында чечетка сыман идәнгә нык басып тыпырдап бию гадәте бар. Туйларда сорап биетәләр. Бу якларда туйга чәлпәк алып киләләр. Чәлпәк – майда кыздырылган кабарып пешкән ризык.

Мин Казахстан якларындагы татарлардан ак юл йоласын алып кайтып, Казанда куллана башладым – кешегә бик ошады. Аның өчен идәнгә 15 метрлы ак җәймә җәелә. Ак юл башында киленне егетнең әти-әнисе каршы ала. Каршылаганда матур теләкләр, зикерләр, догалар әйтелә.

Пенза татарларында Кавказ халыкларындагы сыман, ирләр белән хатыннар төрле залларда да утырырга мөмкин. Аларда бал-май йоласы да, чәк-чәк тә, бавырсак та юк. Әмма чәйнек борыныннан яшь киленгә баллы чәй эчертү йоласы бар. Ул ширбәт дип атала.

Чувашстан, Ульян мишәрләрендә, Самара өлкәсенең төньягында, Татарстанның төньягында арчи дигән йола очрый. Ләкин, Чирмешән арчие Чувашстан арчиеннан аерыла. Шыгырданныкы үзара илтифат күрсәтү, бүләк бирешүгә корылган булса, Самара өлкәсенә кергән Денискин авылындагысы кияү өендә ял итүне аңлата. Бирердә килен чәе, килен токмачы дигән йолаларның кайбер фрагментлары сакланган. Ул Мәскәү татарларында да бар: кайтып китәргә өлгермәгән кунаклар килен кулыннан чәй эчә. Кайбер урыннарда ул алъяпкыч йоласы буларак та үтә. Киленгә каенанасы алъяпкыч бәйләтә, килен кунакларга торт тарата. Алъяпкыч кесәсенә кунаклар акча сала.

Әпипә биюе – Урта Азия татарлары туйларындагы йола. Чәк-чәкнең вак версиясе – Бохара кәләвәсе дә Үзбәкстан татарларында сакланган.



Түбән Новгород яки Мәскәү татарларында чынаяк, стакан йоласы сакланган. Һәр кунак татарча җырлый яки такмак әйтә. Бу мәҗбүри. Җырдан соң акчаны җилпәзә кебек күрсәтеп салалар. Аннары чәй эчеп куялар.

Татар дөньясы күп төрле. Безгә башка халыкларның йолалары да кучкән, үзебезнеке дә бар. Ләкин, ни кызганыч, күбесе аларның бетеп бара. Милли йолаларны пропагандалау буенча мин дә зур эш алып барам. Туй алып баручы буларак, бу минем кесәмә суга, әмма рухыма канатлар куя. Милли йола дип авыз ачсаң, туй үткәрүчеләр башта кабул итми. Чөнки алар өчен туй – инстаграмдагы пафос. Минем өчен миллилек – ул гадилек, туганлык, җылылык һәм татарча җыр-бию.

Мин җайлап кына һәр туйда бал-май йоласын, кыз елатуны да оештырам. «Торт белән генә булмый, бавырсак, чәк-чәк булса кирәк», – дим. «Казлар да булмасмы икән?», – дим. Ешрак очрый торган милли йолаларны тәкъдим итәм.

Башкортстанда булсам, аларга хас йолаларны тәкъдим итәм, әйтик, поднос өстендә бию. Бу – бик дәртле йола. Ул Башкортстан татарларыннан башкортларга да кергән. Поднос өстендә сикерә-сикерә биеп, подносны изеп-сытып бетерәләр. Шул вакытта киленнең итәк астына, кияү ботинкасы астына акча салалар.

Милли туй йолалары саклансын өчен нишләргә соң? Әлбәттә, татар теленең сәяси дәрәҗәсе югары булып, ул фән, дәүләт, эшмәкәрлек, икътисад, җәмгыять теле булырга тиеш. Тел белән бергә аның тирәсендәге башка иярченнәре – моңы-көе, җыры-биюе, уен-көлкесе, шаярулары, бәйрәмнәре дә сакланачак. Шулай ук зыялыларыбыз: мәдәни хезмәткәрләр, күренекле шәхеслар бертуктаусыз халыкчан, гади, аз чыгымлы йолаларны, уеннарны, татарча җырларны, биюләрне, милли киемнәрне, ризыкларны Инстаграм (яшь киленнәр гадәттә шунда утыра) һәм башка челтәрләр аша күрсәтеп, таныштырып торырга тиеш.

Электрон рәвештә булса да, авыл клубларына туйлар, гаилә, авыл, урам, коллектив бәйрәмнәре буенча әзер сценарийлар, программалар, музыкаль язмалар таратылса, онлайн укулар, мастер-класслар, дәресләр, тренинглар, семинарлар уздырылса – болар барысы да безнең миллилегебезне саклап калуда зур эш булыр иде.

**Гамил НУР,**
**«Супер тамада» мәктәбе җитәкчесе**

Фоторәсемнәр авторның архивыннан

# ТАТАРЛАРДА БӘБИ АШЫ КИТЕРҮ ЙОЛАСЫ

**Бәби туу кеше өчен әһәмиятле вакыйга булып һәм һәр халыкта бу уңайдан күп төрле һәм үзенчәлекле йола гадәтләре башкарылып килә. Татар халкында бәби ашы китерү традициясе бар.**

Бу йоланы без Татарстанда яшәүче татарлар тормышы аша өйрәндек – ул республиканың барлык төбәкләрендә дә таралган. Төрле урыннарда «бәби ашы/бәбәй ашы», «бәби чәе/бәбәй чәе» дип атыйлар. Ул бәби хөрмәтенә беренче сый буларак билгеләнә, ягъни, яңа туган кешене ризыклы итү – аның үз өлешен булдыру, муллык теләү. Ул яңа туган бәби хөрмәтенә шул йортка күчтәнәчләр китерүдән тора – бәби ашы алып бару/бәби чәе алып бару. Кайбер урыннарда «бәби боткасы», «бәби мае» дип тә атыйлар – бу күчтәнәч эчендә нәкъ шул ризык булуын аңлатырга да мөмкин, яки атама гына булып, эчендә башка ризык булуы да бар. Йоланың атамасы ничек булуына карамастан, ул үзенә билгеләнгән функцияләрне үти.

Бәби тапкан хатын-кыз янына күчтәнәч белән бару – күркәм күренеш. Нигездә камыр ризыклары китерәләр – кабартма, коймак, гөбәдия, бәлеш. «Элек бер тәлинкә коймак иде, я бер тәлинкә кабартма булыр иде» (С.Г. Галимовадан (1925 елгы) язып алынды, Саба районы Килдебәк авылы); «Элек менә кабартма пешерәдериек инде. Күп кеше шуңа күп итеп сыер маен салып алып килә ие. Кем нәрсә алып килә ала инде, гөбәдия дә була» (С.З. Закировадан (1924 елгы) язып алынды, Арча районы Күпербаш авылы); «Ну үзеңнең пешергән әйбер инде анда, күзикмәкме, дучмакмы, бәлешме. Алар кайнар көе тәмле бит инде бәбәйләгән хатынга» (К.С. Волковадан (1939 елгы) язып алынды, Мамадыш районы Ташлыяр авылы). Күчтәнәчнең камыр ризыкларыннан торуы аны китерүченең мөмкинлегеннән генә чыгып эшләнми, ә бәлки, баланың бәхетле һәм мул тормышта яшәвен дә тәэмин итә дип санала. Бала тапкан хатын әлеге күчтәнәчләрнең барысыннан да авыз итеп карарга тиеш. Информантлар фикеренчә, бу аның организмын ныгыта, көч кертә.

Бәби күчтәнәче арасында аш-су гына түгел, бала табучы хатынга һәм бәбигә бүләкләр дә була. «Кызның ата-анасы бәбигә мендәр, киез, юрган, күлмәк-ыштан алып килә» (Ф.А. Закировадан (1931 елгы) язып алынды, Арча районы Мөндеш авылы);



Яшел Үзән районы С.К. Гыйматдинов исемендәге Осиново гимназиясе укытучылары – Гүзәл һәм Илнур Вафиннар, Гөлгенә Гатауллина

«Элек күлмәкләр, бер метр ситсы иде инде анага, балага вак-төяк кием-салым алып киләләр иде. Кайсы кеше җаулык белән керер иде инде» (С.З. Закировадан (1924 елгы) язып алынды, Арча районы Күпербаш авылы).

Бәби ашының бер мәгънәсе – хатын-кызның ана буларак танылуы. Әлеге кучтәнәчләрнең хатын-кызлар тарафыннан китерелүе дә шуңа бәйле. «Бәбиләгән хатынга ашау китерә. Нинди дә булса тәмлерәк ризык китерә, хәлсезләнмәсен дип, авызына төрле ризыклар керсен дип» (М.И. Шакировадан (1937 елгы) язып алынды, Теләче районы Иске Җөри авылы). Моннан тыш, хатын-кыз яшь ананың сөте булсын дип тә кайгырта – төрле ризыктан авыз иткән хатын-кызга сөт төшә дип саный информантлар. Бәби тапкан хатынның хәлен белү йоласына мотивацияләр дә табылган. Ышануларга караганда, бәби тапкан хатын белән кул биреп күрешү дә файдалы: «Бәби тапкан хатын янына кереп хәлен белсәң, кырык ел эшләгән кыйтылыгың, гөнаһларың бетәр ди» (А.Г. Галиуллинадан (1942 елгы) язып алынды, Яшел Үзән районы Бишнә авылы); «Бәби тапкан хатын белән ике кулыңны биреп күрешсәң, бөтен гөнаһың бетәр ди» (Г.Я. Мостафинадан (1944 елгы) язып алынды, Алексеевск районы Тигәнәле авылы). Бу ышанулар икенче бер ышануларга охшаш («Бала туган йортның морҗасына карасаң да, саваплы»). Әлеге ышанулар арасында бәби ашын тиз арада китерергә киңәш ителгәне дә бар: «Бәби ашын бала тапкан көнне үк китерсәң, бигрәк саваплы булган» (С.З. Закировадан (1924 елгы) язып алынды, Арча районы Күпербаш авылы). Хәзер әлеге традиция башкачарак төсмер алган. Хатын-кыз бәбәйләү йортыннан кайткан көнне аның иң якын кешеләре генә килә, башкалар ана белән бала бераз ныгыгач кына бу йортка аяк баса.

Өйгә бәби ашы китерү белән бергә татарларда «бәби туе» үткәрү традициясе дә бар: кунаклар билгеләнгән вакытка мәҗлескә чакырыла. Кайбер очракларда исем кушу йоласы белән берләштерелә. Әмма бу сирәк була торган хәл, чөнки «бәби туе» бәбиләгән хатын тернәкләнеп беткәч кенә уздырыла, ә исем бала туган беренче-икенче атналарда ук кушыла.

Татарстанның татарлар яшәгән барлык төбәкләрендә дә «бәби туе» уздырыла. Моның белән бергә төрле урыннарда «бәби ашы», «бәби чәе», «бәби боткасы» һәм «бәби мае» атамалары да кулланыла.

«Бәби туен» соңрак үткәрү баланың һәм ананың беренче 40 көндә күз тиючәнлегенә бәйле. Шунлыктан аларны ят күзләрдән яшереп торырга тырышалар. «Баланы кырыгына шае кешегә күрсәтсәң, күз тиюе бетми, гел җылый торган була» (Ф.А. Сабирҗановадан (1941 елгы) язып алынды, Биектау районы Казаклар авылы); «Баланы кырыгына хәтле чит кешегә күрсәтмибез. Кырыгыннан соң гына ярый» (Г.Р. Гыйльмановадан (1974 елгы) язып алынды, Теләче районы Алан авылы). Кырык көннән соң баланы кешегә күрсәтергә ярый, «бәби туе» үткәрелә. Кунаклар кучтәнәчләрен бала янына куеп калдыра. Бу очракта «бәби туе» социаль-демонстратив функция үти – баланы җәмгыятькәияләштерә. Әлеге мәҗлеснең тагын бер максаты – ул туганнарны бергә җыя. «Ул инде ике якның да кешеләрен якынайту, аралаштыру. Аннан соң инде изге теләкләр теләү өчен» (С.З. Закировадан (1924 елгы) язып алынды, Арча районы Күпербаш авылы). «Бәби туена» кунаклар кучтәнәчләр һәм бүләкләр белән килә.

Шулай итеп, бәби күрергә килү татарда балага мул тормыш теләү, аны социумга таныту-ның бер ысулы. Бу йола шулай ук бәбәйләгән хатынның сөтен арттыру теләген күздә тота, туганнарны берләштерү вазыйфасын үти, йола барышында хәл белергә килүчеләр савап ала. Йола бүгенге көндә дә югалмаган – ул бәби чәе китерү буларак та, бәби ашы уздыру формасында да яшәп килә. Йола авылда да, шәһәр җирлегендә дә дә актуаль.

**Зәлия БРУСЬКО,**
**филология фәннәре кандидаты**

Чыганаклар:

1. Баязитова Ф.С. Халык традицияләре лексикасы: бишек туе (йола һәм фольклор текстлары яссылыгында). – Казан: ТР ФАнең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2012. – 331 б.
2. Брусько З.М. Локальные особенности обряда проведывания роженицы и новорожденного у татар Заказанья // Нематериальное культурное наследие тюркских народов как объект сохранения: сборник материалов Международной научно-практической конференции (16-19 июля 2014 г.). – Казань: Ихлас, 2014. – 592 с.
3. Гаврилюк Н.К. Картографирование явлений духовной культуры (по материалам родильной обрядности украинцев). – Киев: Нуковая дума, 1981. – 279 с.
4. Татары / Отв. ред. Р.К. Уразманова, С.В. Чешко. – М.: Наука, 2001. – 583 с.
5. Фольклор практикасы / Төз. Ф.Х. Җәүһәрова, А.Д. Батталова. – Казан: Алма-Лит, 2009. – 130 б.

# ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ МАТУР ЙОЛАСЫ – КАЗ ӨМӘСЕ

**Быелның ноябрь азагында Арча районы Гөберчәк авылында уен-көлке, җыр-моң һәм авыз суларын китерерлек хуш исле ризыклар белән каз өмәсе оештырылды. Чын каз өмәсе! Әлеге борынгы матур йола «Казан арты» тарих-этнография музее хезмәткәрләре ярдәмендә Мөхәммәт Мәһдиев музее мөдире Халидә Габидуллиналарның өендә узды.**
















Халидә Габидуллина фоторәсемнәре

# «Аһ, синең таушың, канун, чын сихерле могъҗиза...»

## Канун – татар мәдәниятендә XIX йөз уртасына кадәр кулланышта булган гомумшәрык музыка коралы

**Татар халкының урта гасыр дәверенә хас музыка кораллары арасында күпкыллы горизонталь арфа төркеменә нисбәтле, канун исемле уен коралы аерым урын алып тора. Бу уен коралы гомумисламият мәдәниятенең классик катламына турыдан бәйле. Шулай ук, канун татар сәнгатенең бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән бер күренешен тәшкил итә. Шуның өчен канун коралының традицион татар музыкасы тарихындагы әһәмиятен һәм урынын ачыклау, билгеләү, бәяләмә бирү таләп ителә. Татар мәдәниятенә кагылышлы язма чыганакларда аерым тарихи мәгълүматлар бар, этномузыкология белеме өлкәсендә татар канунын өйрәнү проблемасы беренче тапкыр куела.**

Канун коралының татар традицион музыка сәнгатенә мөнәсәбәтен ачыклау буенча татар музыка белгечләре тарафыннан нинди дә булса фәнни эш алып барылмаган булса да, ул Идел буе музыкаль белем мирасында чагылыш тапкан. Әле 1928 елда чуваш милли музыка белеме башында торган Ф.П. Павлов «Чуваш гөсләсе» дигән мәкаләсендә Идел-Кама регионындагы халыкларның гөсләләре килеп чыгышы һәм чыганакларын ачыклаганда бу уен коралының һуннар чорында Кытайдан үтеп керүе турында фараз итә. Бу фаразны ул Кытайда яшәгән төрки таранчы халкында булган «калун» коралының, Ф.П. Павлов фикере буенча, чуваш гөсләсе белән бик охшаш булуына сылтама ясап нигезли.

Әлбәттә, бу коралларның тышкы яктан гына кайбер охшашлыгын алга куеп, чуваш тикшеренүчесенең әлеге фикерен исбатлау итеп кабул итү мөмкин түгел. Шул ук вакытта тарихтан билгеле ки, борынгы чувашларның мәдәнияте, башка төрки халыкларныкы кебек үк, борынгы һәм урта гасырларның башлангыч дәверендә Кытай цивилизациясе тәэсирен кабул итеп формалашкан.

Канун исемле уен коралының хасиятләренә, тарихына, мәдәни күренеш буларак формалашу үзенчәлекләренә тукталыйк. Бу музыка коралы Урта һәм Якын Шәрыкъ илләре сәнгатендә кулланылган иң борынгы күпкыллы уен коралларыннан санала һәм борынгы чор Һинд-Иран цивилизациясенә турыдан бәйле. Без бүгенге көндә белгән канун Гарәб хәлифәлекләре дәверендә яңа сыйфатларга баеган, классик формаларын тапкан һәм ислам дөньясына элитар ислами сәнгать җимеше буларак таралган. Ул шулай кабул ителә һәм аны нәкъ шул яссылыкта тикшерергә кирәк тә.

Шуңа күрә Ф.П. Павловның фаразын ялгыш дип кабул итәргә кирәк. Эш шунда ки, таранчыларда, ягъни Көнчыгыш Төркестан уйгурларында, канун коралының үтеп керүен алар тарафыннан ислам динен һәм ислам сәнгатен (аның дини һәм дөньяви өлешләрен) кабул ителү дәвере белән генә бәйләп була. Чөнки уйгурлар һәм Кытай белән чиктәш төбәктә яшәгән башка төрки кавемнәр Будда мәзһәбендә, аннан соң күпмедер вакыт христиан-манихейлар булып яшәгәндә кулланылган күпкыллы уен кораллары бөтенләй башка конструкцияле булган. Мәсәлән, шундый күпкыллы кораллардан – кункау белән ятаган (җатыган).

Татар мәдәниятендәге урынын эзләгәндә канун уен коралының уйгур, үзбәк, әзәрбайҗан, төрек сәнгатьләрендәге чыгышлары аналогиясенә тукталу урынлы булыр. Чөнки алар да ислам кабул иткән, утрак тормышлы һәм элитар шәһәр мәдәниятен булдырган халыклар.

Урта гасырлардагы хан сарайларында кулланылган барлык классик уен коралларын кулланган кебек үк, Болгарда, Болгар дәүләтенең башка шәһәрләрендә дә канун да яңгырый башлаган. Бу уен коралын суфыйлар яратып үзләштергән һәм аны илаһи бәетләрен башкарганда кулланганнар. Урта гасырларның соңгы дәверендә аны Урта



**Т. Ялчыгол кульъязмасыннан канун (гөслә бит төрки) уен коралының схематик сурәте**

Иделдәге татар дәрвишләре дә еш кулланган. Суфый-дәрвишләр аша бу корал татар халкының гади көнкүреш сәнгатенә үтеп кергән. Бу фикернең хаклыгын исбатлый торган фактлар бар. Татар җәмәгатьчелегенә билгеле булган һәм Т. Ялчыголның, безнең тарафтан еш кулланылган кульъязмасында татар музыка коралларының схематик сурәтләре һәм кыскача язылган белешмәләре бар. Анда өчпочмаклы күпкыллы уен коралы схемасы бар.

Төзелеш күрсәткечләреннән карасак, өчпочмак рәвешле коралның кыллары озын катетка параллель. Гомуми схема буенча бу коралны Урта Азиядә кулланылган канун коралы белән идентификацияләргә мөмкин. Әмма Т. Ялчыгол бу коралны «гөслә бит төрки» дип атый.

Идел буе халыклары (псалтыр тибындагы) гөсләләре белән Т. Ялчыголның «гөсләсен» чагыштырып карасак, алар бер-берсенә бөтенләй охшамаган. Эш шунда ки, Идел-Кама буе халыкларының (мари, удмурт, чуваш һәм керәшен татарлары) гөсләләре конструкциясе нигезен ярым ай, яисә ярым түгәрәк кыса тәшкил итә һәм трапеция формасы кебек күз алдына китереп була.

Т. Ялчыгол, суфичылык мәзһәбенең нәкышбәнди юнәлеше вәкиле буларак, бу уен коралын аның чын исеме белән, канун дип атарга тиеш була. Әмма бу уен коралы халык арасында гөслә исеме белән киң таралган булганга, ул аны гөслә бит төрки исеме белән терки. «Канун» атамасы урынына «гөслә» атамасын куллану, урта гасырларның соңгы дәверендә татар халкының ислами сәнгатенә Идел-Кама буенда күрше булып яшәгән мөселман булмаган халыкларның йогынтысы белән дә аңлатыла.

Т. Ялчыгол Спас өязе борынгы Болгар хәрабәләре буенда төзелгән хәнәкәләрдә яшәгән татар дәрвишләренең гөслә коралын (канун) куллануы турында үзенең «Рисаләи Газизә» әсәрендә телгә ала. Бу уен коралы XVIII-XIX йөз башында шактый популяр һәм урта гасырларның классик дәверендәге, ягъни XVI йөз уртасына кадәрге булган башкаручылык традицияләре сакланган булуы турында сөйли.

Татар җәмгыяте XIX йөз уртасында, «яңа вакыт» дәверенә күчкәч, татарлар арасында канунда (гөслә бит төрки) уйнау традицияләре күләмле күренеш буларак яшәештән туктый. Әмма канун турындагы истәлекләр милли хәтер почмакларында булса да саклана.

Мәсәлән, XX гасыр башындагы милли зыялыларыбызның күренекле вәкиле булган шагыйрь Шәехзадә Бабич (1895-1919) милли сәнгать мирасына, тарихка, милли мәдәният тамырларына зур ихтирам белән караган. Ул ислам тарихын бик яхшы белгән, Урал буе төбәгенең ислами мәркәзе саналган Троицк каласы суфыйлары белән якыннан таныш булган, аларның көйләп зикер, касыйдә, газәлләр әйткәннәрен игътибар белән тыңлаган. Әлбәттә, ул Троицкидагы Нәкышбәнди тәрикате халкасын җитәкләгән мәшһүр ишан Зәйнулла Рәсүлев белән дә таныш булган. Суфыйлар белән очрашу, алар мохитен, халәтен белү, күрәсең, аңа «Канун» исемле шигырь иҗат итәргә бер этәргеч биргәндер. Әдәбият белгече Галимҗан Гыйльманов искәртеп киткәнчә, Ш. Бабич үзе дә канун коралында уйный белгән һәм аңарда Урта Азиядән килеп укыган «Галия» мәдрәсәсе шәкертләреннән өйрәнеп, бәет, мөнәҗәт мәкамнәрен башкара алган[1].



Канун. Низами Ганҗәвинең «Искандәрнамә» әсәренең Бохара нөсхәсендәге миниатюрадагы канун сурәте контурлары. 1571-1572 еллар

## КАНУН ТЫҢЛАГАНДА

Сине тыңласам, канун, төрле авазлар ишетәмен;
Әллә кайларда гаҗәеп моңлы вәгъдәләр ишетәмен.

Шул вакыт Коръән укыйдыр кебек бердәнбер кари;
Шул вакыт җырлый, гүя моңлы Давыт хәзрәтләре.

Кылларың назлы, назың мәгъсүм авазны аңкыта,
Канча тыңлап та туялмыйм, башкалар ник ялкыта?

Аһ, синең таушың, канун, чын сихерле могъҗиза,
Чын рәхәт, җаннар эри, каннар таша, бәгърең өзә.

*Ш. Бабич*

Кадими дәвердәге татар канунында көй башкару техникасы үзенчәлекләрен ачыклау проблемаларына тукталсак, алар хәзерге көндә сакланган гөсләдә башкару техникасына якын булган. Мондый фараз Арча, Балтач районнарында яшәүче керәшен музыкантларының гөсләдә уйнау алымнарыннан чыгып әйтелә.

Кадими татар канунын күпкыллы чиртеп уйный торган музыка коралы итеп билгеләргә мөмкин. Башкару алымнарын чагыштырып, типологик төрләргә бүлү яссылыгында караганда, шуны да искәртергә кирәк, шәрыкта күп кенә халыкларның күпкыллы кануны, тарихи үсеш нәтиҗәсендә үзгәреп, чиртеп уйный торган түгел, кылларга таякчыклар белән сугып уйный торган уен коралы буларак билгеле (мәсәлән, андый уен коралын әзәрбәйҗаннар, иранлылар сантур дип атый һәм ул типологик рәвештә цимбал коралы белән охшаш).

Канунда чиртеп түгел, таякчыклар (чүкечләр) белән кылларга суккалап уйнау ысулы мөселман халыклары сәнгатендә дә киң таралган. Мондый күренеш урта гасырларның соңгы дәверендәге татар сәнгатендә дә чагылыш тапкан.

**Геннадий МАКАРОВ,**
**фольклор белгече, сәнгать фәннәре кандидаты, Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе доценты**

Чыганак:

[1] Шәехзадә Бабич. Зәңгәр җырлар. Шигырьләр. Канун тыңлаганда (Фараби хәзрәтләренә багышлыйм) – Казан: Тат.кит. нәшр., 1980. – Б. 83, 429.

# ӘЙ, ДҮДӘМЕ, ДҮДӘМЕ, ГАРМУНЧЫГЫЗ ӨЙДӘМЕ?..



ТАКМАК – ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ МУЗЫКАЛЬ-ШИГЪРИ ИҖАТЫНЫҢ БИК БОРЫНГЫ ЖАНРЫ. УЛ ТӨРКИ ХАЛЫКЛАРДА «ТАКПАК», ЯИСӘ «ТАХПАХ» ДИЕП ЙӨРТЕЛӘ.

Такмаклар бүгенге көндә дә киң таралган, популяр жанр. Ул төрле уеннарда, бәйрәмнәрдә, туйларда халыкның кәефен күтәрү, биетү өчен кулланыла. Татарларда такмакны биемичә бик сирәк әйтәләр. Ул гадәттә биеп әйтелә. Мәсәлән:

*«Эх, Зилем, Зиләле»*
*Менә сиңа уң кулым,*
*Менә сиңа сул кулым.*
*Менә сиңа якын дустым,*
*Менә сиңа куш кулым.*

Кушымта:
*Эх, Зилем, Зиләле,*
*Сандугачым, кил әле.*
*Кил әле, дустым, кил әле,*
*Икәү әйләник әле.*
*Әйләнсәң, әйләнмәсәң дә,*
*Син минеке бит әле.*

Бу жанрдагы бик популяр җырлар булarак, «Әпипә», «Әнисә», «Зәлидә», «Ай зар гизәем», «Әй, икегез, икегез», «Шома бас» һәм башкаларны мисалга китерергә мөмкин. Соңгы елларда Татарстанның халык артисты Хәмдүнә Тимергалиева тарафыннан җырланып популярлашкан «Галигә барам әле» халык җыры да моның матур үрнәге.

Такмакта төп урынны төгәл ритм, дөресрәге, төгәл ритмга буйсынган көй алып тора. Ә сүзләр көйгә буйсына. Алар биюнең хәрәкәтенә, кыланышына бәйле, яисә ул биючене чакыра, өнди, кыстый, хуплый, шаярта. Көйләр, гадәттә җиңел, тиз отышлы, гади, сүзләре дә әйтер өчен шома, ишетер өчен хуш, күңел өчен ятышлы була.

# БИЮ ТАКМАКЛАРЫ




Такмаклар күп очракта музыкаль инструмент вазифасын да үти, анда музыкаль сонор авазлары төркеменә кергән л, м, н, ң авазлары еш кулланыла, кабатлана. Бу ярым тартык авазлар, сузык авазлар белән аралашып, бик ягымлы яңгыраучы сүзләргә әверелә. Мәсәлән:

*Әллиләү генәем,*
*Бәллиләү генәем..,*

яисә

*Бас, кызым, Әпипә...*

Такмакларда шулай ук бер үк авазлар гына түгел, бер үк сүзләр дә кабатлана. Мәсәлән, күренекле җырчы Әлфия Авзалова башкаруында безгә таныш булган такмакта «ялындыра» сүзен алыйк:

*Әй, дүдәме, дүдәме,*
*Гармунчыгыз өйдәме?*
*Өйдә булса, килсен әле,*
*Биетеп китсен әле.*
*Ялындыра, ялындыра*
*Ялындыра – килми ул.*
*Килмәсен дә, йөрмәсен дә,*
*Бию көен белми ул.*

Шулай итеп, такмаклар – шаян көйләр, текстлар белән яшәүче җыр жанры. Аларны башкару өчен җырчыдан бик зур осталык, сыгылмалылык, эмоциональ байлык, хәрәкәтчәнлек, дикция, ритмны тою, җитезлек, бию осталыгы һәм башкалар таләп ителә.

Татар сәнгате осталарының репертуарында да такмаклар очрый. Беренче осталардан Гөлсем Сөләймәнованың репертуарын гына алыйк, алар анда шактый урын алып тора («Шома бас» һәм башкалар). Такмакларны җыеп эшкәрткән шәхесләребезнең берсе – музыкант, композитор, җырчы Мәрьям Рахманкулова. Хәнәви Шәйдуллин башкаруында «Ай, дубр-дубая», «Тары җире, киндер җире», Вафирә Гыйззәтуллинаның «Бондюк кызы Зиләйлүк» һәм башкалар татар музыка сәнгате тарихына кергән әсәрләр.

Хезмәт белән дә бәйле такмаклар була. Аларны «Хезмәт такмаклары» дип йөртәләр. Мәсәлән, өмә белән эшләгәндә, каз йолкыганда, киндер сукканда, йон эрләгәндә, ирләр бүрәнә күтәргәндә, печән чапканда – эшне җиңеләйтү өчен, кәефне күтәрү өчен, көч өстәлсен өчен җырлаганнар. Җыр белән вакыт үткәне дә сизелми, армыйсың да кебек. Салих Сәйдәшев эшкәртүендә «Тула басу» җыры бик популяр, ул инде күп еллар Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле репертуарында.

Халык телендә бәет, мөнәҗәт, такмакка карата «җырлау» төшенчәсе кулланылмый, «бәет әйтү», «мөнәҗәт әйтү», «такмак әйтү» диләр.

**Наилә ЯХИНА,**
**шагыйрә, композитор**

Дмитрий Петриченко фоторәсеме

# һӘР БИЗӘКТӘ – КҮҢЕЛ ҖЫЛЫСЫ

**Келәм туку – бик борынгы һөнәр. Ул кешелек сүсчел материаллардан җеп ала башлагач ук барлыкка килгән. Сәнгать фәннәре докторы Фуат Вәлиев татар халык сәнгате тарихына багышланган монографиясендә билгеләп үткәнчә, төксез келәмнәр туку татарларның борынгы бабалары булган күчмә халыкларда зур урын алып торган һәм алар иҗатында күчмә халык мәдәниятенең бер формасы буларак сакланган. Келәмнәр, асалы паласлар станокларда тукылган һәм гадәттә берничә җәймә кушып тегелгән, чит-читләре каймаланган. Ютазы районының Бәйрәкә авылында келәм тукучы осталарның берсе – кулдан туку уникаль технологиясе белән эш итүче Тәнзилә Мәрданшина яши. Аның өендә агач туку станогы әле дә сафта.**

Тәнзилә апа Мәрданшина 1952 елда Ютазы районының Яссы Тугай авылында туа. Мәктәпне тәмамлагач, Башкортстанның Октябрьск шәһәрендәге 31 нче училищеда укып, тегүче-моторист һөнәрен ала. 1974 елда кияүгә чыгып, гаилә Бәйрәкә авылына күченә.

Тукучы осталары белән данлыклы булган Бәйрәкә авылында яшәүче каенанасы Тәнзиләгә кулдан эшләнгән келәм бүләк итә. Гаҗәеп матур була ул! Тәнзилә ханым үзе дә шундый келәм тукырга кызыга башлый. Кул эшенә оста – тегә, чигә һәм бәйли белсә дә,





Каенанасы бүләге – кулдан тукылган келәм Тәнзилә ханымның йорт диварын әлегәчә бизәп тора

туку эшенә шактый соң – 60 яшендә генә керешә.

Ниһаять, кыюлыгын җыеп, авылның оста тукучылар нәселеннән булган 85 яшьлек Зөләйха Газизова янына килә. Тәнзилә апа беренче айларда аның һәр кул хәрәкәтен хәтеренә сеңдерергә тырышып, күзәтеп кенә тора. Ә берничә айдан беренче бизәген ясый, әкренләп туку һөнәрен үзләштерә.

Тәнзилә ханым күршедән күршегә кереп, иске паласлар җыя, аларның һәр бизәген дәфтәренә күчерә. Сызымнар буенча туганнарыннан агач туку станогы ясатып ала. Шуннан соң ул бар булган буш вакытын шушы станок янында уздыра башлый, камилләшкәннән камилләшә.

Паласның нигезен әзерләү бик вак эш, зур түземлек сорый. Монда аңа ире Кәшиф яисә Зөләйха апа ярдәмгә килә. Алар идәнгә озын җепләрне тезеп салалар, тиешенчә үрәләр, аннары станокка урнаштыралар. Җепләрне дөрес итеп куюга гына да тулы бер көн китә. Алар аз гына да буталырга тиеш түгел, югыйсә эшләгән эшең юкка чыга, яңадан башларга туры килә.

Тәнзилә апа эшләгәндә игътибарын читкә юнәлтми, чөнки һәрдаим җепләрне һәм рәтләрне санап, бизәк җепләренең юнәлешен



карап торырга кирәк. «Ялгыштыңмы – паласны кире сүтәсе була, – дип көлә Тәнзилә апа. – Унар сантиметр араны кире сүткән чаклар була. Ялгышларны төзәтми калдырсаң, аны башкалар кабатлаячак бит».

Палас нигезе өчен «Ирис», «Нарцисс» дип аталган йон җепләре кулланыла. Паласның үлчәме заказ бирүченең теләгеннән, җеп калынлыгыннан һәм бизәк зурлыгыннан тора.





Гадәттә озынлыгы 1,5-2 метрлы, киңлеге 65 сантиметрлы келәмнәр тукыла.

### Останың паласлары

Тәнзилә апаның беренче шәкерте – кызы, аңа оныклары Раилә белән Азалия дә кушыла. Бәйрәкә мәктәбе укучылары да тукучылык белән кызыксына, Тәнзилә апа алар өчен дә остаз булырга каршы түгел.

Останың эшенә ихтыяҗ зур, заказлар килеп кенә тора. Аның паласлары Бәйрәкә музеенда да саклана, районда уздырылган төрле чараларда күргәзмәгә дә куела, затлы кунакларга эксклюзив бүләк буларак та бирелә. Бөтендөнья татар хатын-кызлары корылтаенда да Зөләйха Газизова белән Тәнзилә Мәрданшиналар палас туку буенча осталык дәресе биргәннәр.

Туку эше Тәнзилә апага акча эшләү һәм балаларына үзеннән ядкәр калдыру мөмкинлеге генә түгел, ә иҗат та. «Хәлемнән килсә гел тукып кына утырыр идем», – ди ул. Күпме палас тукыганын хәзер инде ул үзе дә хәтерләми. Кабатланмас һәр татар бизәгенә аның күңел җылысы салынган.

**Ләйсән ХӘЙРИЕВА, Зөлфия ГАЙСИНА,**
**Ютазы районы мәдәният йорты**
**методистлары**

Алия Михайлова фоторәсемнәре

АЙГӨЛ СИНГАТУЛЛИНА:

# «МИЛЛИ КИЕМ КӨНДӘЛЕК БУЛА АЛА»



**Дизайнер, «Татарча casual» заманча милли киемнәр брендына нигез салучы, «Татарстанның ел сувенирлары – 2018», «Татарстанның иң яхшы товары – 2019» бәйгеләре лауреаты Айгөл СИНГАТУЛЛИНА – рубрикабыз кунагы.**



Айгөл Сингатуллина Лаеш районының Пәрәү авылында туып-үскән, Казан дәүләт университетының журналистика факультетын тәмамлаган, төрле елларда «Ялкын» журналында – корреспондент, «Сәләт» лагеренда – әйдаман-укытучы, «Барс-медиа» оешмасында матбугат секретаре булып эшләгән.





















Айгөл Сингатуллина: «Мөгаен ул минем канымда булгандыр. Минем Зәйтүнә әбием һәм аның бертуганы Нәсимә апа гомер буе авыл халкына кием тектеләр, миңа да матур-матур күлмәкләр тегеп бирәләр иде. Безнең өйдә һәрвакыт тегү машинасы булды.

Тегүчеләр йортына килен булып төшкән укытучы әнием дә тегәргә ярата. Мин дә балачактан чигәргә, макраме үрергә, өлгеләр ясарга яраттым. Әнинең сандыкта яткан күлмәкләрен кисеп, үземә күлмәк тегеп кигәнемне хәтерлим.





Милли киемнәр белән кызыксынуыма безнең классның татар теле кабинетында укуы да тәэсир иткәндер. Кабинет диварлары музейга тиң – читекләр, чигелгән сөлгеләр, милли күлмәкләр эленгән иде.

Берара миңа Санкт-Петербургта һәм Мәскәүдә яшәргә туры килде – шунда бизнеска кереп киттем – бу мода, кием өлкәсе белән бәйле иде. 2015 елда милли бренд булдыру, милли коллекцияләр ясау идеясе туды. Әлбәттә, үзем генә түгел, дизайнер һөнәренә ия партнерым да бар иде. Әмма партнерыңның фикердәш булуы кирәк икән, фикерләребез төрле булып чыкты, ярты елдан юллар аерылды...

Иҗат ягыннан мин үземне таптым дип саныйм. Бүгенге көндә осталарыбыз күп. Без бер максат белән яшибез, бер юнәлештә барабыз. Иптәшем Әнвәр дә минем фикердәшем, зур ярдәмчем. Аның нәселендә дә тегүчеләр булган. Максатыбыз – кешенең миллилеккә ихтыяҗын булдыру, зуррак аудитория белән эшләү.

Без, төрле технологияләр кулланып, күп төрле продукция җитештерәбез. Чигү, аппликация, шелкография һәм башкалар – тукымага бизәк төшерүнең күп төрле ысулларын кулланабыз. Технологияләр күбрәк булган саен яхшырак. Чөнки берсе тукталса, икенчесендә дәвам итәргә мөмкин.

Безнең милли орнаментлар төшерелгән тукымадан тегелгән күлмәкләр, галстуклар, шелкография белән төшерелгән футболкалар, чигелгән пальтолар, сумкалар, аяк киемнәрен көндәлеккә кияргә була. Үзебез уйлап тапкан милли орнаментларны төшереп ясалган тукымаларны Төркиядән, Һиндстаннан, Россия фабрикаларыннан кайтартабыз. Күнне Италиядән алдырабыз. Үземә дизайнер да, оештыручы да булырга туры килә.

Яңа товарны әйләнешкә кертүе катлаулырак булса да, экспериментлардан курыкмаска өйрәндек. Хәзер милли бизәкләр чигелгән кроссовкилар эшли башладык.

Сыйфат ягыннан алдыбызга зур таләпләр куябыз. Безнең максат – клиентлар безнең брендны алырга кат-кат килсен. Бу инде димәк, безнең товар кешегә ошый, яратып киеп йөри һәм тагын алырга килә дигән сүз. Клиентларны кабаттан күрү безгә илһам бирә.

Әлбәттә, товарларыбызның ошамаган якларын килеп әйтүчеләр дә булырга мөмкин, әйберләребезгә карата киңәшләр бирәләр – хәерле нияттән булган тәнкыйтьне дә, киңәшне дә кабул итәбез. Мондый фикерләр безгә алга таба үсеш өчен кирәк».

**Рәзинә НИГЪМӘТУЛЛИНА**

Фоторәсемнәр Айгөл Сингатуллинаның шәхси архивыннан

# БОРЫНГЫ ӘСӘРЛӘРЕБЕЗДӘН «БАБАХАН ДАСТАНЫ»

**Таһир-Зөһрә вакыйгаларына багышланган Урта гасырлар әдәби ядкярләребездән «Бабахан дастаны» – халкыбызның саф мәхәббәт тойгы-хисләрен ачык һәм тулы чагылдырган, шул ук вакытта рухи-мәдәни күзаллау һәм милли карашларын берләштергән, иҗтимагый да, табигый да фикерләре берлегенә корылган бөек әсәр. Ул, ничәмә чорлар алмашып һәр яңа буында гаделлек тойгыларын тәрбияләгән һәм яшәткән. Аның өлгесендә әдипләр үз кабатланмас әсәрләрен иҗат иткәннәр, халыкта аның белән авыздаш җырлар, кыйссалар барлыкка килгән. Бу тәэсир бүген дә дәвам итә.**




«Дастаны Бабахан» («Бабахан дастаны») белән бәйле фәнни эзләнүләр әле бүген дә бара. Аның авторы Кылыч Сайяди икәнлеге беркайчан да бәхәс тудырмады. Чөнки әсәрендә шагыйрь үзен кат-кат шул исемдә белдерә. Дөрес, аерым очракларда ул үзен Сәйф Сайяди дип тә атый. Бу факт сорау тудырмаска тиеш кебек. Әмма ни өчен ул үзен гарәпчә исем белән дә атаган, төрки-татар вариантында да күрсәткән? Бәлки, автор шуның белән «Сәйф» яки «Кылыч» исеменең тәхәллүс икәнлеген күрсәтергә теләгәндер? Әллә монда башка сәбәпләр дә роль уйнаганмы? Аның «Сәйф» дигәне – гарәпчә, «Кылыч» – төркичә, икесе дә бер үк исем, бер үк мәгънәгә ия дип, мәсьәләне җиңел генә хәл итәргә дә мөмкин. Әмма төрки исемнәрне йөртү, кушу тарихта аерым чорларда һәм халыкларда гына булганлыгын искәрсәк, моның да әһәмияте зур булуына төшенербез. Димәк, мәсьәлә гади генә түгел икән. Ә «Сайяди»га килсәк, ул тагын да катлаулы.

Сайяди (яки Сәйади, Сәййади, Саййади – бу төрлечә язылуларының сәбәбе бары тик грамматик кагыйдәләрне аңлау-аңлату үзенчәлегеннән генә килә) – нисби исем, ягъни автор үзен туган төбәгенә, шәһәр-авылына яисә бербер җирлеккә, гаиләгә (фамилиягә), халыкка, кабиләгә нисбәт итүеннән. Шунлыктан аны, мәсәлән, «Сайяд шәһәреннән булгандыр» дияргә тулы нигез бар, дибез. Андый аталыштагы кала хәзерге Төркестанда бар. Ул Амудәрья елгасының сул як ярында, Төркмәнабад (Чырҗау) шәһәреннән көньяк-көнчыгышка таба 47 км ераклыкта, 1939 елдан – шәһәрчек, аңа кадәр – авыл, ә 2016 елда гына шәһәр дәрәҗәсен алган. Аның башка төрле тарихы безгә мәгълүм түгел, шундый исемдәге башка бер авыл яки шәһәр бардырмы-юктырмы – белмибез.

Урта гасырларда Кавказда, Аракс елгасы буйларында, борынгы Ереван (ул вакытта «Ируван» дип аталган) тирәсендә Чухуры-Сагад (Сәгадәт чокыры, Бәхет үзәнлеге)

булган. Чыңгыз хан яулары заманнарында бу тирәләргә, монголлар кысрыклап китереп, Урта Азиядән кара-коюнлы (ягъни кара-куйлылар) халкы килеп урнашкан, һәм хәтта Әрмәнстан иле белән дә аларның хөкемдарлары кайбер чорларда идарә иткәннәр. Галимнәр, ул кара-куйлыларның беренче хөкемдары Сәгад исемле булган, шуңа күрә бу төбәкне «Сәгад иңкүлеге» дип атаганнар, диләр. Моның белән ул җирләрнең Сәгад (Сәгадәт) хөкемдарныкы икәнлеген белдергәннәр. Угыз кабиләләре белән кыпчаклар кушылып, берләрендә – «Сәгад иңкүлеге», икенчеләрендә «Сайяд чокыры» буларак әйтелеп йөртелгән. Монда кыпчаклар исә кара-куйлылар аталган угызлар килгәнче үк яшәгәннәр, көтүлекләре белән күчмә тормыш корганнар. Ир-егетләре күрше дәүләтләрдә хәрби хезмәттә торган, аларның мәнфәгатен яклап, яуларда йөргәннәр. Тормыш кәсепләре шуннан гыйбарәт булган. Ә гаиләләре шушы үзәнлектә күчмә тормышта тирмәләр корып гомер сөргән. Монгол яулары белән беренче тапкыр очрашканда да, алар шул хәлләрендә булган. Кыпчак ханнарыннан Күнчак (Кончак, Көнчак) ханның улы Чура (Юра, Жорж) шушы биләмәләрдә хуҗа саналган, Җәбе нойон һәм Сөбүдәй баһадур җитәкчелегендә монголлар явы аларны Төньяк Кавказга китәргә мәҗбүр иткән. Галимнәр фикеренчә, кара-куйлылар күченеп килгәндә, бу иңкүлек инде буш калган. Ә бәлки, кыпчаклар үз кардәшләрен – угызларны яннарына сыендыргандыр?

Кызыклы фактларның берсе: татар халкының Г. Тукае кебек үк, әрмәннәрнең XVIII йөз шагыйре Саят-Нова (Арутюн Саядян) бар. Ул шушы төбәк белән бәйле тәхәллүс йөрткән түгелме? Азәрбайҗан шагыйре Шаһ Хатаи (Исмәгыйль Хатаи, 1487-1524) да кайбер әсәрләрендә шундый нисби имзада үзен күрсәтә торган булган, чөнки ул – ак-куйлылардан (ак-коюнлы), ә алар бу иңкүлекне XV йөздә яулап алган, аны «Сайад» («Саад») дип атап йөрткәннәр. Исмәгыйль Хатаи шунда үскән. Ул Нәсими шигърияте иҗатында өлге иткән, хоруфиларның шигырьләрен әдәби идеал саннаган.

Шулай итеп, «Сагад» яки «Сайяд» дип аталып йөртелгән ул иңкүлек-үзән – «Чухуры-Сайяд» («Чухуры-Сагад», «Чухуры-Сайад», «Чохур Саад» вариантларында да, халыкларда, асылда, тел-сөйләм үзенчәлекләре чагылышында төрлечәрәк аталып йөртелгән) – Урта гасырларда Кавказда шактый билгеле төбәкләрдән булган, аны шагыйрьләр үзләренең нисби исемнәрендә дә күрсәткәннәр...

...«Дастаны Бабахан»да автор үзен Кылыч Сайяди, Сәйф Сайяди, Кылыч Сайяд һәм Сәйф Сайяд исемнәре белән төрлечәрәк атый. Ул – Кылыч та, ул Сәйф тә, ул Сайяди да, ул Сайяд та. Әмма Кылыч исеме – гарәптәге Сәйф исеменең төркичә варианты гына, Сайяд та шул ук нисби Сайяди, башка төрле исем түгел.

Сәйф Сайяди тезмәсе фарсы грамматик кагыйдәсе нигезендә төзелгән. Тәрҗемә итсәк, «Аучы кылыч» дигән төшенчә чыга. Шуннан нәрсә, диярбезме?

Борынгы грек мифологиясендә Орион образы бар. Ул озын буйлы, нык гәүдәле, күркәм затлардан исәпләнә, данлыклы аучы буларак мәгълүм. Үлеменнән соң аны күк йөзенә күтәргәннәр, һәм ул шунда йолдызлык булып балкып яна башлаган. Орион йолдызлыгы менә шул аучы инде. Гарәп телендә «аучы» сүзе «сайяд» була.

Орионның иң якты йолдызларыннан алтынчысы астрономия фәнендә бүген дә «Сәйф» дип атала. Димәк, «Сәйф Сайяди» берни дә түгел, ә чыннан да, «Аучы кылыч» дигән мәгънәгә ия булып, автор тарафыннан башта ук махсус шулай, тәхәллүс итеп сайлап алынган, «Орион йолдызлыгының Сәйф (Кылыч) йолдызы» дигән төшенчәдән гыйбарәт булып чыга. Ә бу исә авторны ачыклау мәсьәләсен тагын да катлауландыра. Шунысы да бар: Орион Сәйфе, ягъни Сәйфе Сайяди гарәп телендә «Сәйфел-җәббар» дип аталып йөртелә, термин буларак гарәп китапларында шулай кулланыла, әмма ул да шул ук «Аучы кылыч» дигән мәгънәгә ия. «Сәйф Сайяди», димәк, фарсыныкы, фарсы теле грамматикасы кануннары нигезендә үзара ярашкан. Әмма алар икесе дә гарәп сүзләре икәнен онытмыйк. Мәгънәдә икесе арасында каршылык юк, «Кылыч Сайяди» исә, төрки «кылыч» сүзе булганы өчен, «сайяд» сүзе гарәптән, ә сүзләрнең үзара ярашулары фарсы грамматик кагыйдәсенә нигезләнгән булуга карамастан, барыбер дә төркинеке. Гарәп-фарсы-төрки ареалында барлыкка килгән. Бу исә әсәрнең шушы халыклар арасында тудырылуы хакында сөйләмиме?..

**Фәрит ЯХИН,**
**профессор,**
**филология фәннәре докторы**

**Кылыч Сайядиның «Бабахан дастаны» текстыннан өзек, әдәби үзенчәлекләре сакланып, бүгенге телебезгә тәрҗемәдә тәкъдим ителә.**

## БАБАХАН ДАСТАНЫ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!*
*Син – караңгы көнем, минем айдай якты йөзем юк,*
*Кереп гөл арасына нишлим, анда йөререм юк.*
*Аерылышу утында калдым, дуслар, ни кылырмын,*
*Мине максатка җиткерергә йөртер юлдашым юк.*
*Бу дөнья – тузан, имеш, ничек мин урын табармын?*
*Фикер кылсам, и туганнар, йөрерлек һич даным юк.*
*Адәмнең җимеше – бала, имеш, диләр дөньяда,*
*Миндә юктыр бала, коры тән мин, шуңа җаным юк.*
*Кешенең булса баласы, аның эшләре тыныч,*
*Минем милкемдә, һай, дуслар, һичбер җан-җиһаным юк.*
*Сайяди мин, билгеледер, догам – дәрткә дәрмандыр,*
*Эчемдә – мең татлы хыял, бер балам-җаным юктыр.*

* * *

*Айа дуслар, ишетик бер хикәят,*
*Эчендә сүзләре бар чиксез гаять.*
*Бабахан дигән бер шаһ бар иде,*
*Аның иле-шәһәре Татар иде.*
*Аның баһадирлыгы чиксез иде,*
*Хода үзе чөнки аңа яр иде.*
*Ни-кем алдына килсә – кисәр иде,*
*Күпме дошман булса да – басар иде.*
*Тик бала гаменнән ул елар иде,*
*Күңелдәгесен Хакка сөйләр иде.*
*Аның вәзире, белик, Баһир иде,*
*Аның алдында даим торыр иде.*
*Ул Баһир елады, әйтте теләген,*
*Елау-сыктау белән әйтте сүзләрен.*
*Диде Баһир: – И Аллаһы, Ходаем,*
*Хәзинәләр Иясе, Бер һәм Барым.*
*Сиңа үтенмичә, кемнән сорармын,*
*Үзең Кайгыртучы, ник гамь җыямын?*
*Синең хәзинәң – гыйшык хәзинәсе,*
*Минем сырхавымдыр гыйшык бизгәге.*
*Кылыр үтенеч сиңа бәндә Баһир,*
*Синең алдыңда, имеш, барча булыр.*
*Бабахан һәм «Ходა» дип елар иде,*
*Бала уе йөрәген яулар иде.*
*Икесе шул рәнҗүдә елады күп,*
*Күзенең яше белән йөзен юып.*
*Диде Баһир: – И Кодрәтле Аллаһым,*
*Сиңа үтенеч итәм, и Ходаем.*
*Бу күңелем кошы канат кагадыр,*
*Сиңа үтенеч итеп моңланадыр.*
*Бу солтанга бүләк кылсаң бер бала,*
*Аның белән солтан булса шат анда.*
*Шушы бала белән солтан шат булсын,*
*Барча кайгысыннан ул азат булсын.*
*Миңа һәм кыл ярдәмең, кыл куаныч,*

*Мәгәр табар хаста күңел юаныч.*
*Икесе бер-берсе белән күңелдәш*
*Һәм булырлар, ни җирдә булса, юлдаш.*
*Тугры дусты белән кылды күп дога,*
*Көярләр бу чүлдә мескен һәм гида.*
*Кабул кылды шушы көн күп мөнәҗәт,*
*Теләде Тәңредән бу икәү хаҗәт.*
*Янә башка морадыны димәде,*
*Бу гомеренчә үтәрне җыймады.*
*Бу сүзләрне диде, куйды башыны,*
*Теләмәде үз-үзенең башыны.*

## БАҺИРНЫҢ ТӨШ КҮРГӘНЕ

*Чистарынып, башын куйды бу җиргә,*
*Хыял итмәде башка сүз диярргә.*
*Башын җиргә куюга күрде бер төш,*
*Тәкъдирдә бар иде аларга өлеш.*
*Күрә: солтан белән ул ясаныптыр,*
*Килеп, Аллаһ хозурына керептер,*
*Аллаһ күренмәде, әйтеп исемен,*
*Сөйләп тупсасыннан бар үтенечен...*

## БАҺИРНЫҢ ШАҺКА ТӨШЕН СӨЙЛӘГӘНЕ

*...Бу төшне күргәч, уянды Баһир,*
*Барып солтанга сөйләр ул хәзер.*
*Диде ул: – Төш күрдем мин, падишаһым,*
*Шөкер Аллаһ, җан дус, һәм бетте зарым.*
*Күзен салды сезгә-безгә, газизләр,*
*Аның кебекне белмиләр аңсызлар.*
*Сөенчеме бирерсез бәндәгезгә,*
*Юмартлыгын кылды кайгылы безгә.*
*Сүзен ишетеп галәмнең солтаны,*
*Ходага шөкердә сөенде җаны.*
*Утырган җиреннән чәчрәде-купты,*
*Бу Баһирның кулыннан тотты-үпте.*
*Диде солтан: – Хода баланы бирсә,*
*Аның белән күңел сөенер булса,*
*Угыл булса, икесе дә дус булсын,*
*Икесе бер тән һәм дә бер җан булсын.*
*Икесе бер-берләренә һәм сердәш,*
*Булсыннар шәһәр эчендә күңелдәш.*
*Әгәр кыз булсалар – булсыннар җанаш,*
*Бер-беренә булсыннар гел аркадаш.*
*Бу шәһәр-ил аларга буйсынса һәм,*
*Боларны кылалмас һич кеше әрәм.*
*Бу шартларны диде шаһ һәм торды,*
*Икесе уртада ант сүзе орды.*
*Диде Баһир: – Ай-һай, и галәм шаһы,*
*Бу ант ширбәт шаһларга тапшырасы.*
*Минем чигем шушы, җитмәс бу сүзгә,*
*Булыр бугай бу сүзләр янә үзгә.*
*Бу сүз өстендә шаһ антын белдерде,*
*Аның өчен шушы кыйсса төзелде…*

**Бабахан дастаны. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2020. – 287 б.**



Рамил Әҗимов фоторәсеме

# НАРДУГАН

Нардуган – төрки халыкларның борынгыдан килгән, кышкы Кояш торгынлыгына багышланган бәйрәме. Исеменең мәгънәсенә килгәндә, монголча «нар» (кояш) һәм татарча «туу» сүзләреннән ясалган дип аңлату бар. Димәк, нардуган, «кояш туган» дигән сүз була. Һәм ул, кышның иң кыска көнендә, 21-22 декабрьдә каршы алына.

Бәйрәмдә яшьләр, җыелып, ят киемнәр киенеп, үзләрен танытмый гына йорттан-йортка кереп, җырлап-биеп, уйнап-шаярып, такмаклар әйтеп, йорт хуҗаларына Яңа елда муллык, иминлек, бәхет теләп йөриләр. Араларында ике төп образ – Нардуган Атасы белән Нардуган Анасы була. Алар озын киемнәр киялар. Нардуган Атасы җитен яки тиредән сакал аса, Нардуган Анасы зур яулык ябына, йөзенә корым яисә иннек сөртә.

Башкортлар һәм удмуртлар бу бәйрәмне «Нардуган», чуашлар – «Нартукэн» һәм «Нартаван», эрзялар – «Нардава», мукшылар – «Нардван» дип йөртәләр. Чуаш телендә Яңа елны каршылау бәйрәме дә «Нартаван» дип атала.

20 гасыр башында Нардуган йолалары үзенең актуальлеген югалтып бетерә диярлек. Әмма Алабуга районының кайбер авылларында һәм Саба, Питрәч районнарында бу бәйрәм һаман да билгеләп үтелә.

# Игелекле ИЛТУГАН

*(Әкият)*

Бик күптәннән булган ди бу вакыйга. Ул вакытта әле безнең бабаларыбыз яшәгән җирләрдә Туңбикә патшалык иткән. Ул бик көйсез, нәзберек, үпкәчел икән. Аз гына кәефе китсә дә бөтен дөньяны кар-буранга күмеп ташлый, салкын җилләр истереп, кешеләрне җәфалый. Мондый көннәрдә халык ауга түгел, урамга утын алып керергә дә чыга алмыйча, өйдә утырырга мәҗбүр булган. Кешеләр күз ачкысыз шыксыз бураннан, карлы өермәләрдән тәмам арганнар, ачлыктан, салкыннан тәмам интеккәннәр.

Әмма холыксыз Туңбикәнең бер йомшак ягы да булган. Ул җен-пәриләрдән, кара көчләрдән бик курка икән. Аның бу гадәтен хезмәтчесе Илтуган да белеп алган. Нечкә күңелле, игелекле егетнең, халыкның газапланганын күреп, ничек тә бу өермә-бураннарны туктатасы килгән. Илтуган, дуслары белән киңәшеп, хәйләкәр план корган.

Туңбикәнең бераз гына кәефе яхшырып, буран туктап торган арада, якын-тирәдәге авыллардан җыелган яшьләр, битләрен танымаслык куркыныч итеп буяп, өсләренә ямьсез, сәләмә киемнәр киеп, барабаннар кагып, кыңгыраулар тагып, иләмсез тавышлар белән кычкырып, урамнарга чыкканнар, бөтен дөньяны шау-шу белән күмгәннәр, өйдән-өйгә йөргәннәр. Шулай тавыш күтәреп, Туңбикәне куркытырга теләгәннәр.

Көйсез патшабикә, җен-пәриләр явын күреп, чыннан да куркып калган. Хәтта сөйләшүен дә оныткан. Аңа ярдәмгә Илтуган килгән, янәсе, кара көчләрне куып җибәргән. Котылуына шатланган Туңбикә егетне бүләклисе килгән. Аның соравына Илтуган: «Миңа кояш, җылылык җитми», – дип җавап биргән.

Шул көннән башлап, патшабикә, бөтенләй үк булмаса да, юк-барга тузынуын туктаткан. Ниһаять, халык, җиңел сулаган, кояшлы, аяз кышкы иртәләрдә ауга йөргән, утын ярган, чишмәгә суга барган, балалар рәхәтләнеп тауда шуган.



**Зәмирә ГАРИФУЛЛИНА рәсеме,**
**Балтач, Салавыч күппрофильле лицееның**
**3 нче сыйныф укучысы**

Үзләрен салкын җилләрдән, көчле бураннардан коткарган Илтуганга халык хөрмәтләп «Нардуган» дип исем биргән. Бу сүз борынгы бабаларыбыз телендә «ут туган, җылылык тудырган» дигән мәгънәне аңлата икән.

Бу вакыйгадан соң халык Нардуган бәйрәмен үткәрә башлаган. Ул көн белән төн тигезләшеп, көннәр язга авыша башлаган вакытларда була ди. Бу көнне яшьләр, Туңбикәне куркыткан гадәт буенча, шыксыз киемнәр киеп, йорттан-йортка кереп, кешеләрне көлдереп, күңелләрен күтәреп йөриләр. Өй хуҗалары аларны сыйлап, бүләкләр биреп озаталар. Ә кояш, кешеләрдәге шатлыкны күреп, көннән-көн югарырак күтәрелә, көннән-көн яктырак балкый икән.

**Алинә КАМАЛОВА,**
**Яшел Үзән, С.К. Гыйматдинов исемендәге**
**Осиново гимназиясенең 4 нче «А»**
**сыйныфы укучысы**



**Кышкы манзара. Әлфия НУРХАМӘТОВА рәсеме,
Аксубай төбәкне өйрәнү музее директоры**

# НАРДУГАН – халык бәйрәме

Нардуганның төп кунагы,
Ул шамакай егеттер.
Җирдә уңыш булсын диеп,
Хуҗа аңа белгертер.

Яңа еллар имин булсын,
Бүләк бирә хуҗалар.
Теләк теләп йолачылар,
Хуҗалардан чыгалар.

Нардуган – халык бәйрәме,
Уеннар уйналына.
Халыкның милли җырлары,
Шушында җырланыла.

Берләштерә татар халкын,
Ата-баба йоласы.
Үткәннәрдән киләчәккә,
Милли күпер салынсын.

**Булат КАМАЛЕТДИНОВ,
Нурлат шәһәре, 1 нче урта мәктәпнең 4 нче
«А» сыйныфы укучысы**

# Кыш көне

Нурзия Мирхазова сүзләре
Наилә Яхина көе




*Рәхәтләнеп тау шуабыз,*
*Чыжылдыйлар чаналар.*
*Салкыннан һич курыкмыйбыз,*
*Битләр уттай яналар.*

Кушымта:
*Әй шаярдык ап-ак карда!*
*Сөйли китсәң, сүзе күп.*
*Ауный-ауный ап-ак булдык,*
*Кыш бабайның үзе күк.*

*Мондый чакта мәтәлгәнне,*
*Егылганны кем саный.*
*Урам буйлап кайткан чакта,*
*Беркем дә таный алмый.*

Кушымта:
*Әй шаярдык ап-ак карда!*
*Сөйли китсәң, сүзе күп.*
*Ауный-ауный ап-ак булдык,*
*Кыш бабайның үзе күк.*



# «Әбиемнен СЕРЛЕ САНДЫГЫ»

***Мәктәпкә әзерлек төркеме өчен сценарий***



**Тәрбияче:** Исәнмесез, балалар!
**Балалар:** Исәнмесез!
**Тәрбияче:** Балалар, бүген нинди кояшлы, матур көн! Әйдәгез бер-беребезгә шат елмаюлар бүләк итик әле. *(Балалар бер-берсенә елмаеп карыйлар)*. Менә бит, бүлмәбез тагын да матурланды, яктырып китте.
*(Әби керә.)*



**Әби:** Исәнмесез, балалар, минем кадерлеләрем. Хәлләрегез ничек?
**Балалар:** Бик әйбәт әбекәй, синең хәлләрең ничек? Әйбәт кенә килеп җиттеңме?
**Әби:** Яхшы балалар, Аллага шөкер.
**Әби:** *(Сандыкка күрсәтә.)* Мин буш кул белән килмәдем – сандыгымны да алып килдем.
**Тәрбияче:** *(Сандык янына килә.)*
Әбиемнең күңел сандыгы!
Нинди серләр саклый икән ул?
Гомер буе җыйган хәзинәме,
Әллә инде күңел бизәгеме,
Нинди серләр саклый икән ул?
**Тәрбияче:** Әбекәй, ә синең сандыгың эчендә нәрсәләр бар?
**Әби:** Аны белер өчен, сандыкны ачарга кирәк.
**Тәрбияче:** Балалар, сандык эчендә нәрсәләр бар икән, ачып карыйк әле. *(Тәрбияче белән балалар сандыкны ачмакчы булалар, ләкин ул ачылмый.)* Нишләптер сандыгыбыз ачылмый.
**Әби:**Бәлки сандыкка матур сүзләр әйтеп карарга кирәктер?
**Балалар:** Сандык матур, серле, бизәкле, агачтан эшләнгән, зур, тылсымлы...
**Тәрбияче:** Менә бит, балалар, сандык үзе турында матур сүзләр ишеткәч, ачылып та китте. Ә бәлки бу тылсымлы сандык турында матур шигырьләр дә сөйләп үтәрбез?
**1 нче бала:**
Серле сандык, матур сандык,
Кызыктыра мине күптәннән.
Әйдә, карыйк,ниләр калган икән
Истәлеккә безгә үткәннән.
**2 нче бала:**
Бу тылсымлы сандыкта,
Сакланмый ниләр генә.
Әйдәгез сорыйк үзеннән,
Ачып күрсәтсен безгә.
**Әби:** Әйдәгез, бергәләп карыйк әле, нәрсәләр бар икән бу сандыкта? *(Әби сандыктан чигүле сөлгесен чыгара.)* Менә бу татар халкының чигүле сөлгесе. Аны яшь чакта, аулак өйдә кич утырып чиккән идек.
**Тәрбияче:** Аны «кызыл башлы Казан сөлгесе» дип тә әйтәләр, балалар.



**Әби:** Ә монысы өстәл ашъяулыгы. *(Балаларга күрсәтә.)*. Күрәсезме, нинди матур канәфер, лалә чәчәкләре чигелгән.

**Тәрбияче:** *(Сандыктан тәрәзә пәрдәсен ала.)* Монысы – тәрәзә пәрдәләре. Аларны ак җирлеккә матур кыңгырау чәчәкләре чигеп эшләгәннәр.

**Әби:** Мендәр тышлыгында да кыңгырау, лалә чәчәкләре чигелгән.

**Тәрбияче:** Балалар, ә менә болары нәрсәләр икән?

**Балалар:** Күлмәк белән алъяпкыч.

**Тәрбияче:** Әйе, балалар, карагыз әле, нинди матурлар! Алъяпкычның итәген төрле чәчәкләр, яфраклар белән бизәп чиккәннәр. Ә күлмәге озын җиңле, итәге киңәя төшкән бала итәкле.

**3 нче бала:**
Алъяпкычның бизәге
Әллә кайдан күренә.
Матур лалә чәчәк төшкән
Бик ошады үземә.

**Тәрбияче:** Ә бу баш киемен беләсезме? *(Калфак күрсәтә.)*

**Балалар:** Калфак. Ул татар кызларының баш киеме.

**Тәрбияче:** Әйе, балалар, татар кызлары башларына калфак кигән. Аларга матурлап, лалә чәчәкләре, өч яфрак бизәкләре чигелгән. Ә малайлар нәрсә кигән?

**Балалар:** Түбәтәй.

**Әби:** Безнең ир-егетләребез түбәтәйне бик яратып кигәннәр. Бүгенге көндә аны әтиләр, бабайлар милли бәйрәмнәрдә, мәчеткә барганда кияләр.

**Тәрбияче:** *(Түбәтәй күрсәтә.)* Карагыз әле, балалар, бу түбәтәй нинди матур! Түбәсе алтын җепләр, энҗеләр, төрле төстәге ташлар белән бизәлгән. Кырыйларына матур үсемлек бизәкләре төшерелгән.

**4 нче бала:**
Әнием туган көнемә
Бүләк итте түбәтәй.
Шундый матур түбәтәем,
Үзем кебек бәләкәй.

**5 нче бала:**
Әнием ак сәйлән белән
Чиккән яшел бәрхеткә.
Баш түбәмдә – түбәтәем,
Мин бүген бик бәхетле.

**Тәрбияче:** Балалар, ял итеп алыйк әле. Мин сезгә яңа уен алып килдем. Уеныбыз «Түбәтәйле» дип атала. Түбәтәйләрне урындыкка куеп, тирәсендә биеп йөрибез. Көй туктауга, тиз генә түбәтәйләрне киеп, урындыкка утырырга тырышабыз. Кемгә урын җитми, шул кешегә җәза бирелә.

*(«Түбәтәйле» уены башкарыла.)*

**Тәрбияче:** Балалар, безнең әбекәй бик матур итеп киенеп килгән. Аның өстендә нинди киемнәр бар, әйдәгез атап китик әле.

**Балалар:** Бала итәкле күлмәк, камзул, күкрәкчә, алъяпкыч, калфак, йөзек, чулпылар, алка, беләзек, чүәк, читек.

**Тәрбияче:** Дөрес, балалар. Мондый киемнәр, бизәнү әйберләре, чиккән сөлге-ашъяулыклар мөгаен сезнең өегездә дә бардыр.

**Әби:** Без яшьлегебездә кичке уеннарда табышмаклар әйтешергә ярата идек. Сез яратасызмы? Сезгә дә табышмаклар әйтим әле:

Әнием ак сәйлән тезеп,
Чиккән яшел бәрхетне.
Ул үзем кебек бәләкәй,
Ә исеме … .
*(Түбәтәй)*

Җырлый-җырлый сәхнәләрдә
Аларның биер чагы.
Кызларга бик килешә
Башындагы … .
*(Калфагы)*



Баш-аяксыз – буе бар,
Гәүдәсе юк – кулы бар.
(Кулмәк)

Биле бормалы, үзенең кулы юк.
(Камзол)

Бер тычканга ике койрык.
(Чабата)

Тамчылары ялтырый,
Тамалмыйча калтырый.
(Алка)

**Әби:** Булдырдыгыз, балалар. Бик дөрес җавап бирдегез.

*(Балаларга «Алъяпкычны һәм камзолны татар орнаментлары белән бизәү» дип аталган дидактик уен тәкъдим ителә.)*

**Тәрбияче:** Әйдәгез, балалар, туп белән дә уйнап алыйк. Мин сезгә тупны атам, ә сез тотып алырга тырышыгыз. Тупны тоткан балага сорау бирәм. Сорауга дөрес җавап биргән очракта, сез кул чабарсыз, ә җавабы дөрес булмаса, аягыгызны тыпырдатырсыз. Сез әзерме? Уенны башлыйбыз.

– Татар малае нинди киемнәр кия?

*(Камзол, түбәтәй, читек, билбау, чабата, күлмәк.)*

– Татар кызлары киеме?

*(Кәзәки, читек, туфли, калфак, яулык, алъяпкыч, чабата, бала итәкле күлмәк, күкрәкчә.)*

**Әби:** Балалар, мин сезгә бүген бизәр өчен рәсемнәр – кызларга – калфаклар, малайларга түбәтәйләр бүләк итәм. Төркемнәрдә төсле карандашлар белән буярсыз.

**Балалар:** Рәхмәт, әбекәй!

*(Әби китә.)*

**Тәрбияче:** Балалар, әйдәгез бергә, түгәрәккә басып, «Кәләпүш» җырын җырлап алыйк.

*(Балалар «Кәләпүш» җырын башкара. Р. Вәлиева сүзләре, Л. Батыр-Болгари көе.)*

**Тәрбияче:** Балалар, сез бүген бик тырыш, актив булдыгыз. Рәхмәт! Татар халкының милли киемнәре турындагы мәгълүматларны онытмассыз, күңел түренә салып куярсыз дип ышанам.

**Алсу ГАРИПОВА,**
**Арча, Үрнәк балалар бакчасы тәрбиячесе**

Автор фоторәсемнәре

# ТУТЫРГАН ТАВЫК



**Бүген бездә кунакта – танылган аш-су остасы Резидә ХӨСӘЕНОВА. Резидә Кыям кызы Хөсәенова – тумышы белән Буа районы Вольный Стан авылыннан, «Тәмле булсын!» рестораннар челтәре җитәкчесе, Татар ашлары һәм мәдәнияте Халыкара ассоциациясе президенты, Татарстан Республикасының атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре.**

– Җир йөзендә өч изге һөнәр бар диләр: кешеләрне ашату-тукландыру, дәвалау һәм гыйлем тарату. Ач карынга зиһен керми дигәне дә бар. Бабаларыбыз да, башта – тәгам, аннары – каләм дип, юкка гына әйтмәгәндер. Димәк, кешеләрнең тамагын туйдыру мөһимрәк була түгелме?! Аллага шөкер, Ходай миңа әнә шундый мәртәбәле, изге һөнәр насыйп итте, – ди Резидә ханым.

***Кирәкле ингредиентлар:***

*1 данә тавык,*
*8-10 данә йомырка,*
*200 грамм сөт яки сөт өсте,*
*Тоз, борыч тәменчә.*

## Җиде сорау

**1** ***– Татар хатыны пешерә белергә тиешле өч ризык?***

– Татар хатыны уклаудан да ризык пешерергә тиеш. Бу нәрсә дигәнне аңлата? Хатын-кызның уклавы булдымы, димәк оны бар дигән сүз. Ә инде оны булган хуҗабикә камырдан нәрсә генә пешерми. Токмачлы аш, бәрәңге һәм коймакны, минемчә, һәр хатын-кыз пешерә белә.

**2** ***– Татар ир-аты яраткан өч ризык?***

– Яраткан хатыны күңел җылысын кушып пешергән һәр ризык ир-ат өчен тәмле була. Шулай да токмачлы ашны, пәрәмәч белән бәлешне барысы да ярата.

**3** ***– Ир-ат йөрәгенә юл ашказаны аша дигән сүз белән килешәсезме?***

– Икенче төрле аны мәхәббәт – ашказаны аша килә, диләр. Чыннан да шулай, килешәм. Ресторанымда узган никах туйларында яшь киленнәргә дә: «Иреңне тәмле итеп ашатырга тырыш, ул кайтканда өстәлеңдә һәрчак ризыгың торсын», – дип киңәшләр бирәм.

**4** ***– Сәяхәтләрдә йөргәндә кайсы як татарлары нинди милли ризык белән сыйлыйлар? Моңарчы күз күрмәгән, ят ризык белән сыйлаганнары булдымы?***

– Төрле җирләрдә, төрле илләрдә булганым бар. Әмма безнең татар халкындагы кебек тәмле, милли ризыклар бер кайда юк. Кая гына барсам да, токмачлы ашымны сагынып кайтам.

**5** ***– Ресторанызда сез генә пешерә торган «фирменный» ризыгыгыз бармы?***

– Әлбәттә. Тутырган тәкә «Тәмле булсын!» ресторанында гына пешерелә. Ул минем «фирменный» ризыгым.




**6** ***– Француз мәкале «хатын-кыз юктан да скандал, салат һәм эшләпә ясый белә», ди. Сезнең юктан да ясалган салатның рецепты ничек?***

– Акыллы хатын-кыз беркайчан да скандал ясамый дип уйлыйм. Ә мин үземне акыллы хатын-кызга саныйм. Һәр хатын-кызның суыткычында кишер, кәбестә, чөгендер, бәрәңге табыла. Шуларны пешереп болгатасаң да, салат килеп чыга. Әмма бүген мин сезгә бик тәмле һәм тиз генә ясала торган салат рецепты тәкъдим итәм. Аның өчен дүрт төрле ингредиент – ысланган тавык ите, алма, виноград, сельдерей сабагы кирәк. Барысын да шакмаклап турап, тәменчә тоз белән борыч сибеп, каралмасын өчен лимон согы сыгып, майонез белән каймак кушылмасын болгатасың да, искиткеч тәмле салат килеп чыга.

**7** ***– Балачак нинди ризык белән хәтерегезгә уелып калды?***

– Мин ишле гаиләдә үстем. Әни гаиләне туендырыр өчен җидешәр ипи сала иде. Без йокыдан торуга шул ипи камырыннан кабартма пешереп куя. Әй, шул кабартмаларның тәмлелеге! Әле дә тел очында. Аннары әнинең әнисе – Мәсрүҗиян әбинең тутырган тавыгын сагынам. Тутырган тавык безнең Буа якларында еш пешерелә иде. Никахмы ул, өй туемы, бәби ашымы, өй бурасы күтәрүче осталарны ашатумы – кызыл тастымалларга төреп алып килә иделәр. Безнең Мәсрүҗиян әби дә 700-800 граммлы тавыкларны, зуррак булсын диптер инде, һәрвакыт тутыра иде. Ак яулыгын артка таба бәйләп, бала итәкле күлмәген алъяпкычына кыстырып, аны керосинкада пешерә иде. Кызу-кызу йөргәнгә «Җилфер әби» дигән кушаматы да бар иде. Балачактан күреп үскәнгәме, мин дә яратып пешерәм аны. Бүген журнал укучыларыбызга да шуны тәкъдим итәм.



*1. Тиресе ертылмаган тавыкны баштан бармак, аннары аш кашыгының арты белән сак кына арка, түш, бот тиресен иттән аерабыз*



*2. Муен тиресен җеп белән бәйләп куябыз.*



*3. Аерым савытка йомырка сытабыз, тоз, борыч, туралган яшел әнис сибеп, сөт яки сөт өсте кушып туглыйбыз.*



*4. Катнашманы тавыкның түшеннән акрынлап кына тутырабыз һәм агач таякчыклар белән элэктереп куябыз.*



*5. Буш итеп кенә марля белән төрәбез дә, кайнап торган тозлы суга салып, 1-1,5 сәгать пешерәбез. Пешкәндә шартлап китмәсен өчен берничә урыннан инә белән тишеп, һавасын чыгарабыз.*



*6. Табынга кисәкләргә турап, яшелчәләр белән бизәп чыгарабыз.*

***Ашларыгыз тәмле булсын!***

Дмитрий Петриченко фоторәсемнәре

# ШАХВОРД

Таблицадагы хәрефләр тезмәсеннән, шахмат фигурасы ферзь йөреше (горизонталь, вертикаль, диагональ шакмаклар буенча) тәртибен кулланып, Нардуган бәйрәменә багышланган шигырь юлларын укыгыз.

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Н | у | г | у | г | , | х | б | а | т | ү | т | у | ы | н | е | н | ы | р |
| а | д | а | д | а | н | у | ө | р | ш | г | - | а | л | н | г | н | м | к | Н |
| р | н | р | н | а | җ | м | ә | ы | ә | л | р | о | а | И | ә | о | а | , | а |
| , | а | , | г | а | , | к | м | р | а | ы | К | р | , | р | Й | д | н | р | у |
| н | Н | у | л | ы | б | р | ә | М | г | , | ы | н | е | - | а | ы | д | д | г |
| а | д | а | л | у | о | к | , | ы | н | г | ы | г | н | й | с | у | р | а | |
| р | р | т | л | Т | б | н | з | ы | ы | с | е | ы | т | л | г | а | н | | |
| , | о | с | , | у | ы | а | с | з | п | з | с | у | у | а | Н | ! | | | |
| К | ы | н | л | с | р | т | ч | а | у | ң | к | б | н | , | | | | | |



## ШАХВОРДНЫҢ ҖАВАБЫ – САННАРДА

Бер сан бер хәрефкә туры килә. Шигырь 168 хәрефтән тора.

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1 | 5 | 6 | 14 | 15 | 27 | 28 | 44 | 45 | 62 | 63 | 80 | 81 | 98 | 99 | 116 | 117 | 134 | 135 |
| 2 | 4 | 7 | 13 | 16 | 26 | 29 | 43 | 46 | 61 | 64 | 79 | 82 | 97 | 100 | 115 | 118 | 133 | 136 | 151 |
| 3 | 8 | 12 | 17 | 25 | 30 | 42 | 47 | 60 | 65 | 78 | 83 | 96 | 101 | 114 | 119 | 132 | 137 | 150 | 152 |
| 9 | 11 | 18 | 24 | 31 | 41 | 48 | 59 | 66 | 77 | 84 | 95 | 102 | 113 | 120 | 131 | 138 | 149 | 153 | 164 |
| 10 | 19 | 23 | 32 | 40 | 49 | 58 | 67 | 76 | 85 | 94 | 103 | 112 | 121 | 130 | 139 | 148 | 154 | 163 | 165 |
| 20 | 22 | 33 | 39 | 50 | 57 | 68 | 75 | 86 | 93 | 104 | 111 | 122 | 129 | 140 | 147 | 155 | 162 | 166 | |
| 21 | 34 | 38 | 51 | 56 | 69 | 74 | 87 | 92 | 105 | 110 | 123 | 128 | 141 | 146 | 156 | 161 | 167 | | |
| 35 | 37 | 52 | 55 | 70 | 73 | 88 | 91 | 106 | 109 | 124 | 127 | 142 | 145 | 157 | 160 | 168 | | | |
| 36 | 53 | 54 | 71 | 72 | 89 | 90 | 107 | 108 | 125 | 126 | 143 | 144 | 158 | 159 | | | | | |



**Шахворд җавабы:**
Нардуган, нардуган,
Нардуган, хуҗалар,
Котлы, мөбарәк булсын,
Тормыш түгәрәк булсын,
Мал-туарыгыз артсын,
Колыннарыгыз чапсын,
Игеннәрегез үссен –
Йомыркадай тук булсын,
Нардуган, нардуган!

**Педагогия фәннәре кандидаты, Халыкара педагогик белем Фәннәре академиясе (ХПБФА) академигы Нәҗип ШАКИРҖАНОВ төзеде**

# Истәлекле һәм онытылмас даталар
# 2021

## ГЫЙНВАР

1 гыйнвар
Татар әдәбиятының классик шагыйре Һади Такташның (Мөхәммәтһади Хәйрулла улы Такташев) тууына 120 ел (1901-1931)

1 гыйнвар
Язучы, тәрҗемәче, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре Адлер Камил улы Тимергалинның тууына 90 ел (1931-2013)

2(15) гыйнвар
Композитор, педагог, профессор, СССРның халык артисты, СССР Дәүләт премияләре (1948, 1950, 1970) һәм Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Социалистик Хезмәт Герое Нәҗип Гаяз улы Җиһановның тууына 110 ел (1911-1988)

4 гыйнвар
Рәссам, монументаль сәнгать остасы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Шамил Габдрахман улы Нигъмәтуллинның тууына 70 ел (1951-2004)

4 гыйнвар
Актриса, Татарстан Республикасының халык, Россия Федерациясенең атказанган артисты Фирдәвес Хәбибулла кызы Хәйруллинаның тууына 70 ел (1951-2003)

6 гыйнвар
Баянчы, ТАССРның халык артисты, Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең оркестр җитәкчесе Рәшит Шәкүр улы Мостафинга 75 яшь (1946)

7 гыйнвар
Татарстанның халык язучысы, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Гомәр Бәшир улы Бәшировның тууына 120 ел (1901-1999)

9 гыйнвар
Рәссам, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Б.И. Урманче исемендәге премиясе лауреаты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Россия Федерациясенең атказанган рәссамы, Зөфәр Фоат улы Гыймаевка 70 яшь (1951)

10 гыйнвар
Әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, ТАССРның атказанган фән эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Нил Гафур улы Юзиевнең тууына 90 ел (1931-1996)

13 гыйнвар
Татар әдәбияты классигы – прозаик, драматург, публицист, әдәбият тәнкыйтьчесе һәм җәмәгать эшлеклесе Фатих Әмирханның (Мөхәммәтфатих Зариф улы Әмирханов) тууына 135 ел (1886-1926)

29 гыйнвар
Драматург, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Мансур Аяз улы Гыйләҗевкә 60 яшь (1961)

## ФЕВРАЛЬ

1 февраль
Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Үзәк китапханәсе ачылуга 125 ел (1896)

6 февраль
Фольклорчы галим, шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе Рәшит Фәйзрахман улы Ягъфәровның тууына 75 ел (1946-2008)

10 февраль
Җырчы, ТАССРның халык, РСФСРның атказанган артисты Вафирә Мөхәммәтдин кызы Гыйззәтуллинаның тууына 75 ел (1946-2001)

28 февраль
Шагыйрә, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Шәмсия Гатуф кызы Җиһангировага 70 яшь (1951)

## МАРТ

4 март
Күренекле прозаик, публицист, тәрҗемәче һәм җәмәгать эшлеклесе Афзал (Афзалетдин) Шиһабетдин улы Шамовның тууына 120 ел (1901-1990)

7 март
Җырчы, ТАССРның халык артисты Шамил Сабир улы Әхмәтҗановка 80 яшь (1941)

19 март
Балет артисты, ТАССРның халык, РСФСРның атказанган артисты Камил Гайфулла улы Гайнуллинга 75 яшь (1946)

21 март
Әдәбият галиме, тәнкыйтьче, филология фәннәре докторы, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре, Халыкара төрки академиянең хакыйкый әгъзасы Фоат Галимулла улы Галимуллинга 80 яшь (1941)

26 март
Телевидение дикторы һәм алып баручысы, туган якны өйрәнүче, тарихи открыткалар коллекцияләүче Абдулла Ибраһим улы Дубинга 80 яшь (1941)

27 март
Шагыйрә һәм проза әсәрләре авторы, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Сәйдә Зыялыга (Сәйдә Закир кызы Зыятдинова) 80 яшь (1941)

30 март
Татарстанның халык шагыйре, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Рәдиф Гаташка (Рәдиф Кәшфулла улы Гатауллин) 80 яшь (1941)

**(Татарстан: Истәлекле һәм онытылмас даталар календаре = Календарь знаменательных и памятных дат. 2020 – Казан: Милли китап, 2019. – 200 б.)**







Кадерле укучыларыбыз!
2021 елның беренче яртыеллыгы өчен «Түгәрәк уен» альманахына республикабызның барлык элемтә бүлекләрендә, яисә «Почта России» сайты аша (https://podpiska.pochta.ru Индекс ПА 183 яисә «Тугарак уен» дип җыярга) онлайн да язылырга мөмкин.

Индексыбыз – ПА 183
Өч айга язылу бәясе – 182 сум 18 тиен
Ярты елга язылу бәясе – 364 сум 36 тиен

БЕРГӘ БУЛЫЙК, ДУСЛАР!